Another novel by Orhan Pamuk "My Name Is Red" ("Benim adim Karmizi") [27] is also notable for its poetics. It is based on the "short story" technique popular in Eastern literature: a work built on a detective story creates the feeling of a set of fragmentary events. In the novel, based on the attributes of a detective story, such as an unsolved mystery, an open ending and a criminal who accidentally exposes himself, the author uses almost all kinds of "the author's masks". The novel has several different historical and cultural levels, in a beautiful and skillful form it reveals the differences in the artistic and aesthetic laws of Western and Eastern cultures. To express his thoughts about life and the world around, Orhan Pamuk uses the genres of "oriental miniature" and "Husni writing" (Arabic calligraphy) as the central theme of his work, which is highly artistic from an aesthetic point of view. The author emphasizes that the pure spiritual talent of the subtlest sensation is no longer found among modern Turks, which indicates a change in their attitude to the world. Here, the writer again touches upon the topic of the Turks' self-determination. At the same time, in this world of culture, which is the proof of divine purity, as Yu. Kristeva notes, "we come across various intrigues and murders": it exposes the frailty of life and people, emphasizing that life is "multifaceted" (See: [40, p. 237]). It also says that preachings, based on Islamic law, deviate from the truth as they are following false motifs and archetypes.

In Tatar and Turkish literatures there are also works written within the framework of metaphysical realism. This type of literature aims to reveal the metaphysical level of life, that is, based on spiritual research, it depicts in a peculiar way the hidden places of the human heart, the mysterious and unknown sides of the world creation. In Tatar literature, "metaphysical realism" is considered to be a unique technique. Realism remains at the basis of this technique, with addition of "hidden world", "hidden reality" and "real reality" parallels. In Tatar literature, these are the works "Kanatsyz akcharlaklar" ("Wingless Gulls") by Fauzia Bairamova, "Nigez" ("Native Hearth") by M. Galiev and works by M. Kabirov, Z. Makhmudi. All of them are based on the philosophical elucidation of the essence of man in the light of the eternal struggle between man and society. This is the philosophy of human existence.

In some of Fauzia Bayramova's works (05.12.1950), this thought is conveyed through the inner world of a person and is closely connected with the experiences of his soul. In most of the writer's works, Man is alone when he comes face to face with Fate, which represents inevitability. It is worth paying attention to another interesting point: F. Bayramova unites a Human, consisting only of a world of dreams and feelings, with Life on Earth. And in the end, he emphasizes that in this world it is very difficult and even pointless to live without a friend, a close person who understands and loves you.

In her story "Kanatsyz akcharlaklar" ("Wingless Gulls"), which is considered one of the works written within the framework of the Tatar postmodern paradigm, F. Bayramova considers the "body" and "soul" as two separate worlds and makes an overview of their "history" [21]. It is not Ak mangay's earthly life that the story highlights, but the unreal world, in which his soul "wakes up". The author seems to deliberately "deviate" from the realities of life and events. F. Bayramova focuses on aesthetic details by comparing Earthly people and those descending from Heaven. In her opinion, there are two types of people on earth, but even if they meet, they cannot fully understand each other, because their life goals and desires are different. The main idea of the works sets the direction from here: Man is the unity of body and soul, on Earth he is able to achieve happiness only through the unity of his Mind and Soul, his belief in Allah, his ability to live along the path that our Creator has determined [69, pp. 31–32].

The course of metaphysical realism is embodied in the work of the Turkish writer Elif Shafak (25.10.1971). In his works, written in English, "Aşk" ("The Forty Rules of Love") [28], "The Architect's Student" ("Ustam ve Ben" [29], he highlights the archetypal problems associated with the formation of the Turkish nation, the Turks' way of life in different eras. The unhurried «study» of their lives through the collection of didactic ideas is a successful feature characterizing the writer's works. The philosophical aspect of

E. Shafak's work "Forty Rules of Love" ("Aşk") is determined by a postmodernist technique, based on opposition, de-mythologization (destroyer) and re-mythologization (creator). The main characters of the work are Zalaletdin Rumi and Shamsetdin Tabrizi. The story is based on forty letters, written by Sh. Tabrizi to the poet Rumi, thereby the author destroys the usual religious doctrine (discourse) of Turkish national history and in its place establishes a new species-metanarrative form, grounded on Tabrizi's words about Life, about what should be its essence. Turkish scholars explored this work for historical correctness. They spoke out against presenting the secretly strange relationship between Tabrizi and Rumi as a mere novel, passing the verdict: there are no historical facts confirming this. However, for the readers who understand that the work was written within the framework of the postmodern paradigm and to the literary critics it is clear that the work belongs to metaphysical realism, and a new "myth" has been created about these two great personalities. In the work "Forty Rules of Love" ("Aşk"), E. Shafak reveals the meaning of the concepts "faith", «mind»; emphasizing that behind these concepts there are dark forces that always push the Turks onto the wrong path, towards chaos, death and thoughtless actions. The work consists of several levels. At the first level, the Tabrizi-Rumi relationship is transmitted through the creation of the atmosphere of the era, while at the second level, this is the field of the Turkish Nation and Life. The writer points out that the Turks should not lose their national face, their national self-consciousness; to achieve this it is necessary to rely on the philosophy of such great personalities as Rumi and Tabrizi. In the work, the concept of chaos differs from the "chaos" in the works of I. Anar and O. Pamuk: despite the fact that events are narrated fragmentarily in the form of a "narrative", "past-present-future" on the same time line. Here, on the contrary, there is an escape from chaos: by avoiding chaos a person will not become a simulacrum (false copy) of man, which will lead to his return to his essence by joining the Truth. On the advice of Tabrizi, Alif Shafak realizes that only a systematic life and the understanding of the essence of the "Word" ("logos"), coming from Truth, is the only way to get rid of chaos.

## Results

1. Postmodern tendencies in Tatar and Turkish literatures are reflected at the level of content and in the form of narration when various techniques and motifs characteristic of postmodernism are used. Although there are similarities in the postmodern philosophy of Turkish and Tatar literatures, we find the diversity of national archetypes, underlying national cultures, the originality of the writers' views on the world and lifestyles and different postmodern approaches.

2. In both literatures, writers do not go beyond national cultural and historical discourse in choosing a plot, in restoring historical and cultural events. Therefore, in both literatures, postmodernism has its own strong beautiful face, its own national version, different from Western literature. The works of the writers we have discussed in the article and their works require unique research methods that fit into the framework of the postmodernist paradigm. The new philosophical terms, used in the work, proved to be effective in scientific literary studies.

3. In the postmodern works of Tatar writers, the emphasis is more on the mythological layer, the creation of myths, Turkic and national archetypes. The use of mythology helps the writers to revive the ancient images and elements, preserved in the "historical consciousness" of the Tatar people, "remember" them and revive them in the memory of the modern reader.

4. Myth-making in the works of the Tatar writers enables the authors to reconstruct an unreal model of the world, which is two-sided and two-dimensional. The main force in all works is the construction of an intricate plot, "resurrection" and the introduction of mystical, mythological images and archaic universals. From an external point of view, the writers consciously return to the archaic construction of their works. That is, the authors create their stories in the spirit of ancient legends, through antiquity, using archaic-ancient images, plot elements, and motifs. In many cases, both history and events here are based on the principle of succession. However, through such techniques as allusion and reminiscence, ancient myths, "additions" from literary works, oral folk art of the past penetrates into their works. A collage is made from different eras and different realities.

5. The works of Turkish writers, such as I. Anar, O. Pamuk, E. Shafak, describing the life of a "fragmented", "small" person in Turkish history, mainly deal with the loss of the Turkish nation identity. Approaching history from the point of view of parody, irony, they explore the new values of human life, looking for ways to survive in a chaotically educated society.

6. In the works of I. Anar and O. Pamuk, history ceases to be a chain of events and takes the form of a “narrative” / “text”. It is this quality of a “narrative” that helps us to view history as a collection of events going in different directions. For Turkish writers, the historical process is not a straightforward past-present-future flow, but a world full of chaos dominated by random, sudden events. Randomness is considered especially noteworthy.

7. As a distinctive feature of postmodernism in Turkish literature, it is necessary to note the historical-philosophical (historiosophical) novel, which took its shape in the work of I. Anar. The poetics of this novel differs from the poetics of ordinary historical novels: the plot of the work is considered to be an allusion to the events of the historical past, without accepting historical events as facts. It is this phenomenon in Turkish literary criticism that has caused controversy in relation to the works of Orhan Pamuk or Elif Shafak. Literary critics accuse these works, based on archetypal images describing the formation of the Turkic society and ethnic group, of lacking historical truth. However, researchers overlook the fact that they are written on the basis of postmodern poetry. In fact, these works do not aim to reveal the fate of famous historical figures, including them in the context of historical events, but rather represent dialogues and monologues, such as “The Fate of Turkey”, “Confrontation between Turkey and the West”, “History of the State and the End of the World” .

8. This article is written in the form of a review of postmodern works found in Turkish and Tatar literature. Many unique works and authors in both literatures have not been included in the article. For this reason, both the work of other writers and the works of the writers we have discussed require a more complete and in-depth analysis. The results, presented in the article, may be useful for understanding the postmodernist paradigm in Tatar and Turkish literatures.

## Conclusion

From the foregoing, it is clear that the works in Tatar and Turkish, written in a new descriptive language, openly reflect the incompleteness of the world, the fact that it is impossible to describe reality with only one specific descriptive technique. All this speaks of the birth of new philosophical-aesthetic and socio-cultural concepts about the place, purpose of life, etc. in both Turkic literatures. This, in fact, is a new form of the postmodern paradigm of world perception, a worldview and an artistic expression of the world.

**References**

1. Nigmatullina, Yu. (2002). *“Zapozdalyi modernism” v tatarskoi literature i izobrazitel'nom iskusstve* [“Belated Modernism” in Tatar Literature and Fine Arts]. 176 p. Kazan. (In Russian)

2. Zagidullina, Z. (2003). *Modernizm ham XX gasyr bashy tatar prozasy* [Modernism and Tatar Prose in the Early 20th century]. 207 p. Kazan. (In Tatar)

3. Shamsutova, A. (2003). *Tatar adabiyatynda postmodernistik contseptsiyalarnen chagylyshy* [Reflection of postmodern concepts in Tatar literature]. 36 p. Kazan, Kazan State Humanitarian Institute. (In Tatar)

4. Gümüş, S. (2021). *Modernizm ve Postmodernizm* [Modernism and Postmodernism]. 152 p. İstanbul, Can Yayınları. (In Turkish)

5. Ecevit, Y. (2021). *Türk Romanında Postmodernist Açılımlar* [Postmodernist Expansions in the Turkish Novel]. 247 p. İstanbul, Everest Yayınları. (In Turkish)

6. Emre, İ. (2006). *Postmodernizm ve Edebiyat* [Postmodernism and Literature]. 380 p. Ankara, Anı Yayınları. (In Turkish)

7. Akay, A. (2010). *Postmodernizmin ABC'si* [The ABC of Postmodernism]. 175 p. İstanbul, Say Yayınları. (In Turkish)

8. Aydın, H. (2021). E*leştirel Aklın Işığında Postmodernizm ve Yansımaları* [Postmodernism and Its Reflections in the Light of Critical Mind]. 312 p. Bursa, Sentez Yayınları. (In Turkish)

9. Bingöl, U. (2021). *Dijital Çağda Pusulası Bozulan Şiir – Postmodernizm ve Şiir Üzerine* [Poetry Distorted in the Digital Age – On Postmodernism and Poetry]. 312 p. İstanbul, DBY Yayınları. (In Turkish)

10. Evis, A. (2021). *Türk Romanında Postmodernizm -Teori ve İnceleme* [Postmodernism in Turkish Novel -Theory and Analysis]. 340 p. İstanbul, Kriter Yayınları. (In Turkish)

11. Koçakoğlu, B. (2012). *Anlamsızlığın Anlamı Postmodernizm* [The Meaning of Meaninglessness Postmodernism]. 200 p. Ankara, Hece Yayınları. (In Turkish)

12. Shamsutova, A. (2002). *Tatar adabiyatynda postmodernistik karashlar* [Postmodern Views in Tatar Literature]. Gilmi yazmalar, TGGI. Gumanitariya. October, pp. 45–49. (In Tatar)

13. Khakim, Z. (1997). *Sailanma asarlar* [Selected Works]. In 3 volumes. T. 1, roman. 399 p. Kazan, Taтar.kit.nəshr. (In Tatar)

14. Khakim, Z. (1995). *Agymsuda ni bulmas. Satirik roman* [What You Will Not Meet in Flowing Water. A Satirical Novel]. Khakim Z. Sailanma asarlar. V 3 tomakh.Tom 2, pp. 126-228. Kazan (In Tatar)

15. Gimatdinova, N. (1996). *Bolan* [Deer]. Kyrgyi: povest'lar ham khikayalar. 142 p. Kazan. (In Tatar)

16. Gilmanov, G. (2003). *Albastylar* [Forest Spirits]. 403 p. Kazan. (In Tatar)

17. Gilmanov, G. (2007). *Ocha torgan keshelar: roman, povest'lar, bayannar* [Flying People: Novels, Stories]. 463 p. Kazan. (In Tatar)
18. Magdiev, M. (2009). *Sailanma asarlar*. [Selected Works]. V 4 tomakh. Tom 4, 480 p. Kazan, Taтar.kit.nəshr. (In Tatar)
19. Yakhin, F. (2000). *Ak abilar dogasy: khikayalar, povest'lar* [Ak ebis' prays: stories and novels]. 255 p. Kazan, Taтar.kit.nəshr. (In Tatar)
20. Bayramova, F. (2000). *Bolyn* [A Meadow]. Mon: povest'lar. 272 p. Kazan, Taтar.kit.nəshr. (In Tatar)
21. Bayramova, F. (2000). *Kanatsyz akcharlaklar* [Wingless Gulls]. Kunel Karlygachlarym: povest'lar. 272 p. Kazan, Taтar.kit.nəshr. (In Tatar)
22. Anar, I. O. (1995). *Puslu Kitalar Atlasi* [A Misty Atlas of Continents]. 238 p. Istanbul. İletişim Yayıncılık – Çağdaş Türkçe Edebiyat Dizisi. (In Turkish)
23. Anar, I. O. (1998). *Efräsiyäb'm Hikäyeleri* [The Stories of Afrasiab]. 245 p. Istanbul. İletişim Yayıncılık. (In Turkish)
24. Anar, I. O. (2011). *Kitab-ül Hiyel* [The Book of Cunning]. 144 p. Istanbul. İletişim Yayıncılık. (In Turkish)
25. Anar, I. O. (2007). *Suskunlar* [The Dumb]. 268 p. Istanbul. İletişim Yayıncılık. (In Turkish)
26. Pamuk, O. (2000). *Kara Kitap* [Black Book]. 552 p. Türkiye İletişim Yayınları. (In Turkish)
27. Pamuk, O. (2013). *Benim Adım Kırmızı* [My Name Is Red]. 552 p. Yapı Kredi Yayınları. (In Turkish)
28. Şafak, E. (2009). *Aşk* [Love]. 420 p. Istanbul, Doğan Kitap. (In Turkish)
29. Şafak, E. (2013). *Ustam ve Ben* [My Master and I]. 480 p. Istanbul, Doğan Kitap. (In Turkish)
30. Bart, R. (1994). *Tri vneshnikh prostranstva. Raskol. Vykhod iz tupika. Izbrannye raboty: Semiotika. Poehtika* [Three Outer Spaces. The Split. A Way out of the Impasse. Selected Works: Semiotics. Poetics: Translated from French]. 616 p. Moscow, Izdatel'skaya gruppa "Progress", "Univers". (In Russian)
31. Bodriiyar, Zh. (2006). *Simvolicheskii obmen i smert'* [Symbolic Exchange and Death]. 389 p. Moscow, Dobrosvet, KDU. (In Russian)
32. Liotar, Zh.-F. (1998). *Sostoyanie postmoderna* [Postmodern Status]. Translated from French. 160 p. Moscow, Institut ehksperimental'noi sotsiologii; St.Peterburg, Aleteiya. (In Russian)
33. Ortega-i-Gasset, Kh. (1991). *Degumanizatsiya iskusstva* [Dehumanization of Art]. Ehstetika. Filosofiya kul'tur. 588 p. Moscow. (In Russian)
34. Fuko, M. (1994). *Slova i veshchi. Arkheologiya gumanitarnykh nauk* [Words and Things. Archeology of the Humanities]. 406 p. St. Peterburg, A-cad. (In Russian)
35. Khaidergger, M. (1993). *Vremya kartiny mira* [The Time of the World Image]. Khaidergger M. Vremya i bytie. 447 p. Moscow, Respublika. (In Russian)
36. Kheizinga, I. (1997). *Igra i kul'tura* [Game and Culture]. Kheizinga I. Homo Ludens. Stat'i po istorii kul'tury. 416 p. Moscow. (In Russian)
37. Il'in, I. (1998). *Teatr kak kritika. Maska avtora. Obshchestvo spektaklya* [Theater as Criticism. An Authorial Mask. A Society of the Theatrical]. Il'in I. Postmodernizm ot istokov do nashikh dnei. 255 p. Moscow, Intrada. (In Russian)
38. Man'kovskaya, N. B. (2000). *Ehstetika postmodernizma* [Aesthetics of Postmodernism]. 347 p. Sankt-Peterburg, Aleteiya. (In Russian)
39. Skoropanova, I. S. (2001). *Russkaya postmodernistskaya literatura: novaya filosofiya, novyi yazyk* [Russian Postmodern Literature: New Philosophy, New Language]. 416 p. St.Peterburg, Nevskii Prostor. (In Russian)
40. Çeler, Z. (2021). *JuliaKristeva ve IçimizdekiYabancı* [Julia Kristeva and the Stranger Within]. DoğuBatı Dergisi. P. 56. Pp. 237-243. (In Turkish)
41. Bakhtin, M. M. (2000). *Ehpos i roman* [Epic and Novel]. 304 p. St. Peterburg, Azbuka. (In Russian)
42. Lotman, Yu. (2002). *Zametki o strukture teksta. Kul'tura i tekst kak generatory smysla* [Notes on the Structure of the Text. Culture and Text as Generators of Meaning]. Lotman Yu. Istoriya i tipologiya russkoi kul'tury. 768 p. St. Peterburg. (In Russian)
43. Tyupa, V. I. (2001). *Narratologiya kak analitika povestvovatel'nogo diskursa (Arkhierei A. P. Chekhova)* [Narratology as an Analyst of Narrative Discourse (The Bishop of A. P. Chekhov)]. 58 p. Tver', Tver. gos. un-t. (In Russian)
44. Tyupa, V. I. (2002). *Khudozhestvennyi diskurs: (vvedenie v teoriyu literatury)* [Fiction Discourse: (Introduction to Literary Theory)]. 80 p. Tver', Tver. gos. un-t. (In Russian)
45. Toporov, V. (1995). *Mif. Ritual. Simvol. Obraz. Issledovaniya v oblasti mifopoehticheskogo. Izbrannoe* [Myth. Ritual. Symbol. Image. Research in the Mythopoetic Field. Selected Works]. 624 p. Moscow, Izdatel'skaya gruppa "Progress" – "Kul'tura". (In Russian)
46. Repenkova, M. M. (2010). V*rashchayushchiesya zerkala. Postmodernizm v literature Turtsii* [Rotating Mirrors. Postmodernism in Turkish Literature]. 240 p. Moscow, Vostochnaya literature. (In Russian)
47. Suleimanova, A. S. (2007). *Postmodernizm v sovremennom turetskom romane. Dis. ... kand. filol. nauk. 10 01 03 – Literatura narodov stran zarubezh'ya (literatury stran Azii i Afriki)* [Postmodernism in Modern Turkish Novel: Ph. D. Thesis Abstract]. 216 p. St. Peterburg. (In Russian)
48. Kareva, O. V. (2012). *Postmodernistskaya paradigma v romanistike Ikhsana Oktaya Anara. Avtoreferat dis. ... kand. filol. nauk* [Postmodern Paradigm in the Novels of Ihsan Oktay Anar: Ph. D. Thesis Abstract]. Moscow, 28 p. (In Russian)
49. Shamsutova, A. (2003). *Khazerge Tatar adabiyatynda postmodernistik karashlar ham Zolfat*

*Khakim izhaty* [Postmodern Views in Modern Tatar Literature and Zulfat Khakim's Work]. Gilmi yazmalar, TGGI. No. 11, pp. 17-21. (In Tatar)

50. Gündüz, O. (2012). *İhsan Oktay Anar'ın Kurgu Dünyası/Anar'ın Kurgu Evreninde Postmodern Bir Gezinti* [İhsan Oktay Anar's World of Fiction/A Postmodern Walk across Anar's Fiction Universe]. 254 p. Ankara, Grafiker Yayınları. (In Turkish)

51. Breeva, T. N. (2010). *Natsional'nyi mif v russkom istoriosofskom romane rubezha XX XXI vekov* [A National Myth in the Russian Historiosophical Novel at the Turn of the 20th and 21st Centuries]. 270 p. Kazan, Kazanskii gos.un-t. (In Russian)

52. Kristeva, Yu. (2004). *Izbrannye trudy: Razrushenie poehtiki* [Selected Works: The Destruction of Poetics]. Translated from French. 656 p. Moscow, «Rossiiskaya politicheskaya ehntsiklopediya» (ROSSPEN). (In Russian)

53. Tekin, M. (2017). *Roman Sanatı 1- Romanın Unsurları* [Novel Art 1- Elements of Novel]. 324 p. İstanbul, Ötüken Neşriyat. (In Turkish)

54. Descartes, R. (2018). *Yöntem Üzerine Konuşma* [A Conversation on Methods]. 92 p. İstanbul, Dogu Bati Yayınları. (In Turkish)

55. Shamsutova, A. (2005). *Khazerge tatar prozasynda mif tudyru* [Myth Creation in Modern Tatar Prose]. 479 p. Kazan, «Khәter». (In Tatar)

56. Yung, K. (1991). *Arkhetip i simvol* [Archetype and Symbol]. 343 p. Moscow, Renessans. (In Russian)

57. Yung, K. (1994). *Problemy dushi nashego vremeni* [Problems of the Soul of Our Time]. 336 p. Moscow, Progress, Univers. (In Russian)

58. Shamsutova, A., Karimova, R. (2021). *Mifologizm i fol'klornye motivy v sovremennom tatarskom romane* [Mythologism and Folklore Motifs in the Modern Tatar Novel]. Sbornik materialov Vserossiiskoi nauchno-prakticheskoi konferentsiya «Roman v literature i kul'ture narodov Rossii». Vostochno-Sibirskii gosudarstvennyi institut kul'tury (Ulan-Udeh, 19–21 May 2021). Pp. 85-99. Ulan-Udeh. (In Russian)

59. Gimatdinova, N. (1993). *Sikherche: povest'lar, khikayalar* [Sorceress: Novels, Stories]. 286 p. Kazan. (In Tatar)

60. Galiev, M. (1996). *Nigez: povestlar, khikayalar* [Native Hearth: Novels, Stories]. 367 p. Kazan. (In Tatar)

61. Kabirov, M. (2006). *Makhabbat yangyry: povestlar* [Love Rain: Novels]. 431 p. Kazan. (In Tatar)

62. Karimova, R. (2016). *Tatar Mitolojisinde İyeler* [The Familier Spirits in Tatar Mythology]. Gaziantep University Journal of Social Sciences. No. 15(3), pp. 881–897. (In Turkish)

63. Shamsutova, A. (2006). *Nabira Gyimatdinova izhatynda mifologik katlam ("Bolan" asare misalynda)* [Mythological Layer in Nabira Gimatdinova's Work (based on the novel "Bolan")]. Milli madaniyat. No. 9, pp. 11-19. (In Tatar)

64. Shamsutova, A. (2007). *Zhan surate: yazuchy Galimzhan Gyil'manov izhatyna shtrikhlar* [Soul Image: Some Lines on Writer Galimzyan Gilmanov's Work]. Maydan. No. 4, pp. 87-103. (In Tatar)

65. Ertuğrul, K. (2003). *Türkiye Modernleşmesinde Toplumsal ve Bireysel Özerklik Sorunu: Oğuz Atay ve Orhan Pamuk'la Birlikte Düşünmek* [The Problem of Social and Individual Autonomy in Turkey's Modernization: Thinking Together with Oğuz Atay and Orhan Pamuk]. Doğu Batı Dergisi. P. 22, pp. 91-105. (In Turkish)

66. Zakirzanov, A. (2000). *Yashlegen sagynuchy adip* [The Writer Who Misses His Youth]. Magarif. No. 2, p. 34. (In Tatar)

67. Shamsutova, A. (2003). *Yazuchy Mohammad Mahdiev izhatyna ber karash* [One Look at Writer Muhammad Magdiev's Work]. Kazan utlary. No. 12, pp. 107–115. (In Tatar)

68. Shamsutova, A. (2010). *Khazerge tatar adabiyatynda yanarysh: fanni makalalar* [Renovation in Modern Tatar Literature: Scientific Papers]. 205 p. Kazan. (In Tatar)

69. Shamsutova, A. (2005). *Fauziya Bairamova prozasy* [Fauziya Bairamova's Prose]. Monograph. 120 p. Kazan, "Khәter". (In Tatar)

# XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫ ПОСТМОДЕРНИЗМ МӘДӘНИ КОНТЕКСТЫНДА ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ӘДӘБИЯТЛАРЫ

**Алсу Атлас кызы Шамсутова**,
ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем.Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420008, Казан ш., К. Маркс ур., 12 нче йорт,
aatlas1@mail.ru.

**Мурат Урфәт улы Узун**,
Измит Белем һәм сәнгать мәркәзе,
Төркия, 41100 Кожаэли-Измит ш., Җәм Айдын Илкин ур., 3 нче йорт,
tfimuratuzun@gmail.com.

Мәкаләдә XX гасыр ахыры - XXI гасыр башында татар һәм төрек әдәбиятларындагы постмодернистик концепцияләр яктылыгында әдәбиятның һәм мәдәниятнең күтәрелешендә зур роль уйнаган язучыларның әсәрләре, аларда чагылыш тапкан идея-эстетик, фәлфәфи идеяләр, алымнар тикшерелә. Татар язучылары Ф. Бәйрәмова, З. Хәким, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, М. Мәһдиев, Ф. Яхин, төрек язучыларыннан И. Анар, О. Памук, Ә. Шафакның милли мәдәният үсешен тәэмин иткән проза әсәрләре фәнни тикшеренүнең объекты булып тора. М. Мәһдиев, Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, З. Хәкимнең фәлсәфи карашлары, сәнгатьчә фикерләүләренең хосусиятләре, иҗат кыйблалары XX гасыр ахыры – XX1 гасыр башы әдәби һәм мәдәни контекстында, ә Ф. Бәйрәмова һәм Ф. Яхинның әсәрләре мифологик һәм метафизик яссылыкта шәрехләнә. Төрек әдипләренең романнары Гареб һәм Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнештә, постмодернистик әсәрләр поэтикасы кануннары кысаларында өйрәнелә.

Төрек әдәбиятындагы постмодернистик парадигмага кагылышлы төрле чыганаклардан мәгълүматлар һәм фактлар барлана һәм аларда, бер системага салынып, бүгенге төрек әдәбиятының торышына күзәтү тудыру омтылышы ясала. Хәзерге төрек әдәбиятына нисбәтле язучы Әлиф Шәфәкъ әсәрләре беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертелә. Фәнни эзләнүләрдә чагыштырма-тарихи, типологик һәм герменевтика методларына, культура-тарих мәктәбе кагыйдәләре һәм принципларына таяныла.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, төрек әдәбияты, постмодернизм, миф тудыру, метафизик реализм, нарратив, интертекстуальлек, архетиплар

## Кереш

Мәкаләдә XX гасыр ахырында формалаша башлаган яңа мәдәни парадигма тәэсирендә татар әдәбиятының фәлсәфи һәм рухи эчтәлеге үзгәрүен, татар һәм төрек әдәбиятларын XX гасыр ахыры – XXI гасыр башындагы әдәби процесс һәм мәдәни контекстта шәрехләү максаты куела. Татар язучылары һәм Төркиядәге каләмдәшләре иҗатларында чагылыш тапкан чорның кызыклы әдәби-сәнгати яңалыкларын ачу омтылышы ясала, чагыштырма планда фәнни әйләнешкә кертелә. Тугандаш төрки халыклар әдәбиятының төп вәкилләренең фәлсәфи фикерләре әдәбият белемен өйрәнүнең гыйльми концепциясен формалаштыруга, аның теоретик проблемаларын хәл итүгә, татар һәм төрек әдәбиятларын кеше яшәешен сәнгатьчә гәүдәләндерүнең яңа формалары, тасвирый алымнары белән баетуга үзләреннән өлеш кертәләр. Югарыда ассызыкланган сыйфатлар хезмәт темасының фәнни яңалыгын һәм актуальлеген билгели.

XX гасыр ахырында элеккеге Советлар илендә иҗтимагый формацияләр, чорлар алмашу язучыларның дөньяга карашы үзгәрүгә дә этәрде. 1980 еллардан башлап татар әдәбиятында яңа, постмодернистик юнәлеш барлыкка килә. Татар әдәбиятында чагылыш тапкан яңа фәлсәфи-эстетик карашларны галимнәр төрлечә кабул иттеләр. Мәсәлән, Й. Нигъмәтуллина аны «соңарган модернизм» («запоздалый модернизм») дип атый [1]. Д. Заһидуллина модернизмның бер формасы дип кабул итү хакында тәкъдим белән чыга [2]. А. Шамсутова яңа стилистикага нигезләнгән яңача фикерләүне, әсәр структурасында чагылыш тапкан иҗади-сәнгати үзгәлекләрне «постмодернизм» әдәбияты кысаларында тикшерә [3].

Әлеге мәкаләдә авторлар постмодернизмны махсус формалаштырылган яңа бер мәдәни-фәлсәфи парадигма кысаларында, тормышның барлык якларын да яңача аңлата торган яңа бер алым буларак карыйлар. Бу яңа иҗат алымында әсәр эчтәлеген формалаштыруда әйдәп баручы роль билгеләнә. Көнбатышта 1950-1960 елларда формалашкан постмодернистик парадигма дөньяга башка бер фәлсәфә кысаларында якын килүне таләп итә; аның үз кыйммәтләре бар. Россия һәм Төркия җирлегендә ул XX гасырның 80 елларында үтеп керә. Күренә ки, постмодернизм әдәбиятта яңа юнәлешне барлыкка китерде [3, 45–49 б.].

Төрек әдәбиятында исә 1980 елларда яза башлаган яшь авторлар өр-яңа тематикалы, образлы, яңа сәнгати системага салынган, дөньяны чагылдыруда авангард алымнарга нигезләнгән әсәрләр тәкъдим иттеләр. Төрек әдәби постмодернизмы да XX гасырның соңгы чирегендә – XXI гасыр башына туры килә. Дөнья әдәбияты һәм Көнбатышның әдәби тәнкыйте дә төрек постмодернизмының үзенчәлекле характерын таныды. 2006 елда язучы Орхан Памукка Нобель премиясен тапшыру моңа дәлил булып тора.

Төрек әдәбият белемендә постмодернистик әдәбият хакында Сәмит Гүмүш [4], Йылдыз Эҗәвит [5], Исмәт Эмре [6], Али Акай [7], Хасан Айдын [8], Улаш Бингөл [9] һәм башка галимнәрнең саллы, җитди хезмәтләре бар. Төрек әдәбиятында постмодернизм, күбесенчә, иҗтимагый-сәяси вәзгыять белән, «көнбатыш тәэсиренә бирелү» («вестернизация» яки җәмгыятьне европалаштыру процессы) белән бәйләп карала [10]. Күпчелек төрек галимнәре милли әдипләрнең авангард стилистикасын постмодернизм парадигмасы белән генә бәйләп карамыйлар. Төрек әдәбият белемендәге фәнни дискуссияләрдә төрек галимнәренең күбесе өчен постмодернизм, гадәттә, Көнбатыш феномены буларак кабул ителә һәм шул сәбәпле күпвакыт уңай күренеш буларак бәяләнми [11, 5 б.]. Хәзерге төрек әдәбиятын бәяләүдә каршылыклар да китереп чыгара.

«Тормыш – ул театр», бер әсәр җирлегендә төрле фәлсәфи фикерләрнең кисешүе (интертекстуальлек), Җир тормышын һәм адәм баласының үзен төрле катламнарга аерып каравы кебек концепцияләр, уен, коллаж, реминисценция, аллюзия кебек алымнар XX гасыр урталарында Аурупада постмодернизм теоретиклары тарафыннан фәнни җирлектә өйрәнелә башласа да, Көнчыгыш әдәбиятларында, шул исәптән татар һәм төрек сүз сәнгатьләрендә, алар борынгы чорлардан ук сурәт тудыруның үзәк катламнарын тәшкил иткәннәр. Билгеле булганча, алар әдәби әсәрләрдә үзенчәлекле гәүдәләнеш тапкан шәрык менталитетының нигезендә яталар. Мәкаләдә исемнәре атап үтелгән язучылар исә бу концепцияләрне, алымнарны бүгенге татар һәм төрек әдәбияты җирлегендә яңача үстерәләр, кулланалар. Шул рәвешле сүз сәнгате кысаларында Шәрык һәм Гареб синтезын формалаштыралар, яңача дәвам итәләр [12, 45–49 б.].

**Фәнни хезмәтнең материалы һәм методлары**

Мәкаләдә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар һәм төрек әдәбиятларының актуаль проблемалары белән тыгыз бәйләнгән татар һәм төрек язучылары әсәрләрендә чагылыш тапкан жанр үзенчәлекләре, әсәр поэтикасының төзелеш структурасы, тематик яңалыклар, гомуми әдәби-эстетик фикерләре, концепцияләр фәнни тикшеренү эшенең предметы булып тора. Тикшерү объектын исә З. Хәким [13], [14], Н. Гыйматдинова [15], Г. Гыйльманов [16], [17], М. Мәһдиев [18], Ф. Яхин [19], Ф. Бәйрәмова [20], [21], И. Анар [22], [23], [24], [25], О. Памук [26], [27] Ә. Шафак [28], [29] әсәрләре тәшкил итә.

Мәкаләнең методологик нигезен постмодернистик фәлсәфәне яктырткан һәм әдәби текстны, символлар, билгеләр системасы буларак өйрәнеп, структур анализга корылган заманча әдәби концепцияләр тәшкил итә. Авторлар Р. Барт [30] , Ж. Бодрийяр [31], Ж-Ф. Лиотар [32], Х. Оргета-и-Гассет [33], М. Фуко [34], М. Хайдерггер [35], Й. Хейзинга [36] кебек чит ил галимнәренең, И. Ильин [37], Н. Маньковская [38], И. Скоропанова [39] кебек Россия һәм Yıldız Ecevit [5], Ali Akay [7], Hasan Aydın [8], Zafer Çeler [40], İsmet Emre [6] һәм башка Төркия әдәбият белгечләренең постмодернизм турындагы хезмәтләренә таяна. Шулай ук әдәбият теориясенә нигезләнгәндә, М. Бахтин [41], Ю. Лотман [42], В. Тюпа [43], [44], В. Топоров [45] кебек галимнәрнең хезмәтләре, төрек әдәбиятының торышын тикшергәндә, М. М. Репенкова [46], А. С. Сулейманова [47], О. В. Карева [48] кебек галимнәрнең хезмәтләре дә кулланыла.

Куелган максатка ирешү өчен, киңкырлы мәдәни яссылыкта эзләнүләр алып барылды. Әдәбият белеме өчен традицион саналган анализ төрләренә – әдәби-теоретик, мәдәни-

тарихи, герменевтик, интертекстуаль, структур-семантик, рецептив, чагыштырма-компаративистик методларга, шулай ук яңа булган нарратив анализ, дискурс-анализга да мөрәҗәгать ителде.

Мәдәни–тарихи методның әдәбиятларның милли традицияләр һәм тарихи процесс белән бәйләнештә үсеше хакындагы төп кануны язучыларның иҗатын XX гасыр ахыры – XX1 гасыр башы әдәби барышы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә карарга мөмкинлек бирде. Татар әдәбиятын постмодернистик фәлсәфә һәм Гареб һәм Көнчыгыш мәдәнияте контекстында комплексlы өйрәнү XXI гасыр башы татар иҗтимагый-фәлсәфи, гыйльми, әдәби-эстетик фикерләренең структур компонентларын аерып чыгарырга ярдәм иткән компаративистик методны файдалануга этәрде. Болардан башка әдәби күренешләрне аларның барлыкка килү, үсеше һәм тарихи бәйләнешләр ноктасыннан өйрәнүгә юл ачкан интертекстуальлек һәм тарихилык принцибы да кулланылды.

**Фикер алышу**

Хәзерге татар һәм төрек прозасында постмодернистик концепцияләр чагылыш таба. Татар язучылары арасында постмодернистик фәлсәфәнең ирония, пародия, пастиш кебек алымнарын әдәби әсәр җирлегенә матур үреп бирү, мифологик образны, мотивны куллану һәм аны үзенчә үзләштерү ягыннан Зөлфәт Хәким (11.08.1960) иҗаты кызыклы. З. Хәким әдәбиятка көтмәгәндә килеп кереп, беркемне дә кабатламый торган өр-яңа бер стильдә иҗат итә башлады. Җитмеш елга якын социалистик реализм методына буйсынып яткан татар әдәбиятын ирония алымы, интертекстуальлек белән баетты, тормышның кырыс кануннарына укучының күзен ачарга ярдәм итте. «Зөлфәт Хәким әсәрләрендә Франсуа Рабле дә, Гарсиа Маркес та, Борхес та, Джером Клапка да, Марк Твен да, хәтта Сервантес та бар шикелле тоела»,-дип яза М. Юныс [13, 4 б.].

З. Хәкимнең «Агымсуда ни булмас» (1992) сатирик романы постмодернистик парадигмалар кысасында язылуы белән тагын да игътибарга лаек [14, 126–228 б.]. Бүгенге тормышны реалистик буяулар белән сурәтләүгә корылган әсәргә автор мифологик Су анасы образын кертеп җибәрә. Су анасы хакындагы мотив исә татар шагыйре Г. Тукайның шул исемдәге шигъри әсәреннән алына, ягъни автор әнә шул әкияткә нигезләнә. Әдип татар әдәбиятында постмодернизмның реминисценция алымын файдалана. «Агымсуда ни булмас» әсәре үзенең аһәңе белән алдагылардан аерылып тора, чөнки монда автор үзенең төп максаты итеп совет җәмгыятенә пародия ясауны күздә тота. Романдагы бу алымның үзен тагын берничә дәрәҗәгә аерып булыр иде [49, 17–21 б.].

Пародияне тудыруда авторга «уен» алымы ярдәмгә килә. Шуның нәтиҗәсендә, З. Хәкимнең «Агымсуда ни булмас», «Кишер басуы» һ.б. әсәрләрендә тормыш, дөнья, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте «театр» итеп сурәтләнә. Тормышта һәркем ниндидер роль уйный; алай гына да түгел, кеше төрле ситуациядә үзен төрлечә тота, төрле рольләргә керә. Бу әсәрдә «уен» алымын куллану ягыннан Миңлебаев образы отышлы. «Уен» алымын куллану ул әле геройларның башкарган рольләрен сурәтләү генә түгел. Монда төп «идарәче» – ул язучы, автор. Геройларны теге яки бу көлкеле, фаҗигале ситуацияләргә куеп, ул, беренче чиратта, үзе «уйный». З. Хәким очрагында бу – язучының, үз-үзенә юнәлтелгән, ягъни үзе тудырган дөньяны, процессны күзәтүдән туган канәгатьләнү рәвешендәге уен.

«Су анасы» татар укучысы өчен гади образ яки гади сүзтезмә генә түгел. Безнең хәтердә шундук Г. Тукай, аның шул исемдәге әкият-поэмасы яңара. З. Хәким исә әсәр тукымасына мифик образ кертеп кенә калмаган, ә Г. Тукай әсәреннән бер сюжет сызыгын да файдаланган. Мәрдәнша, «Су анасы»н үзенә карату өчен, Тукай әкиятендәгечә эшләргә тели: имеш, ул алтын таракны урлый, төнлә Су анасы аның артыннан авылга килә; аның килүен этләрнең өрүе хәбәр итә; Су анасы тәрәзәгә чиртә. Бу момент классик әсәрдән алынган «цитата» кулланылу хакында сөйли.

Беренче карашка, реаль чынбарлыкны сурәтләүгә нигезләнгән әсәргә «Су анасы» образы килеп керү үзе үк әсәрнең уенга корылуын күрсәтә. Язучы бу очракта янә бер алым – коллаж алымын куллана. Коллаж алымы фотографиядә, кинофилмьнарда еш очрый. Ул бер әйбернең өстенә икенчесен ябыштыруны аңлата. Әлеге алым әсәрдә пародияне, уен атмосферасын көчәйтүгә хезмәт итә. Димәк, кеше аңына тәэсир итү юлларын эзләү барышында язучы З. Хәким, укучыны үзе сурәтләгән вакыйгалар агышына тартуның төп чарасы итеп, әсәр тукымасына уен алымын кертүне отышлы дип саный. Әдәбиятта исә уен категогиясе пародия тудыруга гына хезмәт

итми. Язучының пародия алымын кулланууның максаты – совет чынбарыгында тәрбияләнгән татар кешесе тормышының абсурдлыгын, алар башкарган гамәлләрнең мәгънәсез, буш, көлке булуын күрсәтү. Бу яктан аның әсәрләре рус, Көнбатыш әдәбиятларындагы «абсурдлык театры» концепциясендә корылган әсәрләргә якын тора. Әсәр текстындагы абсурд элементы бүгенге чынбарлыкның тотрыклы булмавын күрсәтү бурычына хезмәт итә. Милли тарихның, милли тормышның сәнгати эчтәлеген шул рәвешле аңлау язучыга алардан каһкаһә белән көлү мөмкинлеген бирә. З. Хәким татарның дөньяны кабул итүе социалистик дискурс кысаларында формалашуын «гиперперсонаж маскасы» ярдәмендә ачу омтылышын ясый.

З. Хәким иҗатында постмодернистик алымнарның кулланышы ягыннан төрек язучысы Ихсан Анар белән уртаклыклар күренә. И. Анар (Ihsan Oktay Anar, 21.11.1960) – төрек әдәбиятында постмодернистик парадигманың икенче буыны вәкиле буларак билгеле. Бу юнәлешкә реализм аша килгән беренче буын постмодернистик язучылар Орхан Памук (Orhan Pamuk), Назлы Эрай (Nazli Eray), Билге Карасу (Bilge Karasu), Муратхан Мунган (Murathan Mungan), Пынар Кюр (Pinar Kur) кебек шәхесләрдән аермалы буларак, И. Анар постмодернистик фәлсәфәнең «нарратив модификациясе» юнәлешенә якын тора [48, 10 б.]. Аны постмодернизм фәлсәфәсенең сәнгати-эстетик элементлары ачык чагылыш тапкан матур әсәрләр авторларыннан иң көчлесе дип атау урынлы булыр.

1990-2000 еллар әдәбиятында аның иҗаты башка постмодернистик «нарратив язучылар»га (H. Toptas, P. Yugor) караганда өстенрәк күрелә, яратып кабул ителә [50, 7 б.]. «Нарратив» стильдә язылган әсәрләрдә вакыт һәм урын берлеге, каһарманнарны ачу, сөйләм стратегиясе төптән үзгәрүе күзәтелә. Бу исә «автор-текст-укучы» сызыгын тәшкил иткән әдәби багланышның да (коммуникациянең) яңа бер рәвеш алуына сәбәп була. Постмодернистик парадигма төрек әдәбиятында роман жанрының активлаштыруына этәргеч була. Роман жанры эчендә әдәби-сәнгати-фәлсәфи трансформацияләргә юл ачыла. Жанрларара, күпжанрлы романнар барлыкка килә [46]. Роман жанрының яңа формасы булган тарихи-фәлсәфи роман формалаша (рус әдәбият белемендә аны «историсофский роман» дип атау каралган) [51]. Төрек әдәбиятында постмодернистик парадигма кысаларында тарихи-фәлсәфи романны Ихсан Анар башлап җибәрә.

И. Анарның әсәрләре роман-дискурс дәрәҗәсенә җиткерелгән. Алар төп милли концептларга, гомумкешелек һәм архетипик сюжетларга нигезләнә; топосның һәм хронотопның тотрыклыгы белән аерылып тора. Нәтиҗәдә архетипик фикерләүгә, шәхеснең эреп югалуына, аңсызлык катламына корылган романнар барлыкка килә. Тарихи-фәлсәфи сәнгатьчәлелек эмоциональ-эстетик ирония белән тәмамлана. Мәсәлән, И. Анар күп әсәрләрендә дөньяның фанилыгын һәм эсхатологик карашларны карнаваллаштеру алымы ярдәмендә сурәтли. Аның романнарында «яңарыш» һәм «азат итү-ителү» кебек күренешләр очрамый; әмма тормышны, тормышка, дөньяга карашны «кызыклы, ироник җимерү» аша укучы өчен яңа фикерләр, яшәеш хакындагы яңа перспективалар ачыла. Мондый төр әсәрләргә мисал итеп, И. Анарның «Томанлы утраулар атласы» («Puslu Kitalar Atlasi») [22], «Мәкерлек китабы» («Kitab-ül Hiyel») [24], «Афрасиаб хикәяләре» («Afrasiyab'in hikayeleri») [23]. «Телсезләр» («Suskunlar») [25] кебек әсәрләрен китерергә мөмкин.

Бу романнарда И. Анарның милли тарих, милли тормыш хакындагы фәлсәфи карашлары төрек җәмгыятендә яшәп килгән ике төр дискурсны башкача аңлауга һәм аңлатуга нигезләнә. Язучы дини һәм мәгърифәтчелек фәлсәфи дискурсларын кабаттан карарга чакыра. Постмодернистик теориядә бу дискурслар метанарративлар дәрәҗәсендә карала. Роман кысаларында язучы бу ике төр фәлсәфәгә нигезләнгән милли карашлардан каһкаһә аша көлә яки аларны ирония ярдәмендә тәнкыйтьләп үтә. Төрекләрнең дөньяны кабул итүе дини дискурс кысаларында формалашуын И. Анар да «гиперперсонаж маскасы» дип аталган яңа төр хикәяләү алымы аша ача. Тарихи яшәешнең онтологик асылы постмодернистик парадигманың Р. Барт [30], Ю. Кристева [52], В. Тюпа [44], В. Топоров [45] кебек галимнәр нигезләгән «семиотик юнәлеше» рухында кабаттан карала.

Төрек язучысының югарыда ассызыкланган әсәрләрендә тарих, тормыш вакыйгалары тулы нарративка (текстка) гына әйләнеп кала. Тарих дигән күренештән акыл белән уйлау-нәтиҗә ясау катламы махсус рәвештә алып ташланыла;

аның урынына инстинктлар өстенлеге, либидо, коллектив аңсызлык катламы килеп керә. Фәнни ачышлар, яңалыклар да төрек җәмгыяте өчен «белем эзләүгә омтылыш» итеп кенә карала. Нәкъ менә шушы яклары белән төрек постмодернистик әдәбияты татар постмодернистик әдәбиятыннан аерылып тора. Татар әдәбиятында әсәр поэтикасының бу төр катламнары юк дәрәҗәсендә.

И. Анарның «Томанлы утраулар атласы («Puslu Kitalar Atlasi») [22], «Мәкерлек китабы» («Kitab-ül Hiyel») [24], «Афрасиаб хикәяләре» («Afrasiyab'in hikayeleri») [23] роман-трилогиясендә чагылыш тапканча, төрек постмодернистик әдәбиятында вакыйгалар чылбырын беркетеп торучы вакыт чылбыры юк: ул тормыш эпизодларын өзек-өзек бирүгә кайтып кала. «Үткән-бүгенге-киләчәк» төрле вакыт һәм чорлар яссылыгына «ыргытылырга» мөмкин; алар арасында билгеле бер эзлеклелек яки бәйләнеш тә булмаска мөмкин. Язучы романнарының күпчелек каһарманнары тулы канлы геройлар буларак түгел, ә үз йөзләрен югалткан берьяклы кешеләр буларак яшиләр.

И. Анар, «Томанлы утраулар атласы» («Puslu Kitalar Atlasi») [22] романында «хат алымы»н кулланып (epistolary technique), «эпистоляр роман» (epistolary novel) төрен алгы планга чыгара. «Хат алымы» романда ике төрле кулланыла: беренчесе мөстәкыйль хатлар һәм бер-беренә җавап шәкелендәге хатлар булса, икенчесе – кирәк вакытта гына кулланыла торган хатлар рәвешендә күренә [53, 244-248 б.]. Әдипнең тәүге әсәре булган бу роман интертекстуаль багланышларга бик бай. Мәсәлән, әсәр «Carmina Burana»дан алынган цитата-эпиграф белән башлана. Башка бүлекләрдә Коръән һәм Инҗил китапларыннан алынган эпиграфлар ярдәмендә әдәби монтаж ясала. И. Анар әсәрдә француз философы Рене Декар (René Descartes) һәм аның «Yöntem Üzerine Konuşma» дигән хезмәтенә мөрәҗәгать итә: пародия алымын кулланып, аның әсәрләренең исемнәрен алмаштырып роман текстына кертә [54]. Р. Декартның «Фикерлим, димәк мин яшим» афоризмын төрекчә ирония, сүз уены аша ача. «Düşünüyorum, öyleyse varım» җөмләсе урынына «Düşlüyorum, öyleyse varım» («Хыялланам, димәк мин яшим») кебек лейтмотив формасында укучыга тәкъдим итә. Төп герой үз яшәешен бары тик хыяллары ярдәмендә генә тормышка ашкан вакыйгалар дип аңлатырга тырыша. Аның бу карашы автор тарафыннан пародия алымы ярдәмендә тәнкыйть утына тотыла, шул рәвешле бөтен бер төрек милләте өчен хыялланып кына утырмагыз – эшләгез, фикерләгез, тырышыгыз дигән шигарь-девиз тәкъдим ителә.

«Афрасиаб хикәяләре»ндә төрек җәмгыяте «уен»га корылган театр буларак тасвирлана. «Уен» категориясе И. Ильин [37], И. Скоропанова [39], Koçakoğlu [11] хезмәтләрендә тирән аңлатыла. Постмодернистик парадигмада шәхес таркала: үз йөзен генә түгел, хәтта үзен дә югалту баскычына җиткерелә. Шушы ноктадан якын килә торган бәндәләр өчен Яшәү һәм Үлем арасында аерма калмый; үлем дә яшәү өчен бара торган уен-күрәшнең бер формасы буларак кына кабул ителә.

Постмодернистик тарихи-фәлсәфи (историсофский) роман шәкеле язучыга кешене бу рәвешле тасвирлау мөмкинлеген бирә. Тәнзимат чорыннан башланган мәгърифәтчелек һәм дәүләтчелек карашлары мең еллар элек формалашкан ислам фәлсәфәсе тәгълиматлары (дискурслары) белән кушылып, төрек кешесендә «аңлап бетереп булмый торган» шәхесне яки «бөтен нәрсәне дә күтәргә мөмкин» кешене тудыра. Мондый кешенең асылында берничә йөзле «Мин» идеясе, «күпмаскалылык» идеясе ята.

И. Анарның «Томанлы утраулар атласы» («Puslu Kitalar Atlasi») [22] романында сурәтләнгән госманлы чорында мондый шәхесләр әле аз, бары тик Бүньямин һәм Эбрәх-әфәнде кебекләрдә генә күренә. Тәнзимат дәверенә багышланган «Мәкерлек китабы» («Kitab-ül Hiyel») [24] әсәрендә дә мондый «күпйөзле» кешеләр ул кадәр күп түгел: хәйләкәр, мәкерле галимнәр генә. Ә инде XX гасырның уртасында барган тормышны тасвирлауны максат итеп куйган «Афрасиаб хикәяләре» («Afrasiyab'in hikayeleri») романында [23] бу тип бәндәләр күбәя. Җөмһүрият тормышының яңа иҗтимагый-мәдәни парадигмасына яраклашырга теләгән гади халыкның яшәеше ашау, эчү, күңел ачу, җенси ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә кайтып кала. Кешеләрдә мәдәни кануннарны аңлаган, таныган «аңлы» шәхес дигән асыл югала; автор күрсәткәнчә, «Анадолуның гади халкы» җан иясенең нindидер бер төренә әйләнеп кала. Яшәеш тә, адәм баласы да метаморфоза (үзгәреш) кичерә; яшәеш үзенең антитезасына әверелә – аның кадере, кыйммәте аңланылмый. Мәсәлән, персонажларның үз-үзен һәм бер-берләрен үтерүе; яшәүнең төрле

почмакларында кешеләрне күзәтеп йөри торган Үлем-Кеше һ.б.лар. Шул рәвешле, Ихсан Анар күрсәткәнчә, милли архетипны бимазалап торган ерткычлык, адәм баласының аңсызлык өлкәсенең тирән катламнарына яшеренгән куркыныч теләкләре өскә чыга.

2007 елда басылган «Телсезләр» («Suskunlar») [25] романында И. Анарның постмодернистик тарихи-фәлсәфи концепциясенә дидактизм элементлары килеп керә. Шунысы кызык: дидактизм постмодернизм фәлсәфәсенә хас түгел; ләкин ул тарихи романнарның асылын тәшкил итүче катлам. Киләчәкне фаразларга ярата торган төп герой Узун Ихсан образы аша автор «телсез» каһарманнарны һәм укучыны да Хакыйкатьнең күптөрле булу идеясенә инандырырга тели. Язучы фикеренчә, бары тик Хакыйкатьнең күптөрле булуын таныган кешеләр генә котыла ала. Шуңа да ул төрекләрнең котылу идеясе бер линиягә нигезләнгән «логоста» (сүздә) түгел, ә хаоста икәненә басым ясый. Төрек җәмгыятенең асылында ята торган хаослык – адәм баласын коткара ала; кешеләр шушы хаоска күнегергә, анда яшәргә өйрәнергә тиеш. Хәтта «хаосны тудыручының уенына» кушылып, үзләре дә шунда төп роль уйнарга өйрәнергә тиеш. Язучы бары шул вакытта гына күпкырлы Хакыйкатьне танырга була дигән фикерне ассызыклый. Шул рәвешле язучы төрек кешеләренең менталитетын, асылын, аларның «күпкатламлы» булуын ача, бу кешеләрнең акылында, фикерендә нәрсә булуын беркайчан да белеп бетереп булмаячагын билгели. Мондый төр кешеләр белән яшәү өчен аларның үзләре кебек үк «актер», «уенчы» булырга өнди, хәтта шушы уен-театрның тудыручысы булырга кирәк дигән фикерне җиткерә. Аның романнары кырык тартманы хәтерләтә: вакыйгалар тиз куера, бер дәрәҗәдән икенчесенә күчә, үстерелгән саен, артта калган юллар ябылган кебек хис туа – герой үзен вакыйгалар, дөресрәге, хәят, яшәеш капканы эчендә калгандай хис итә. Әмма шул ук вакытта чыгу юлы да күрсәтелә: ул, реализм кануннары буенча эзлекле түгел, ә көтелмәгәндә, очраклы, хәтта параллель чынбарлыкларга «сикерү» аша да булырга мөмкин.

И. Анарның «Телсезләр» романында дини карашлар, татар әдәбиятында чагылган дини карашлар белән чагыштырганда, башка яссылыкта ачыла. Ислам төрекләр өчен бер басым кебек карала: музыкант Әфләтун дини Хакыйкатьтән саңгыраулансан һәм телсез калган, ә күрәзәче Йедикүл – сукырайган. Хакыйкатьне дә алар шушы килеш кабул итәләр: ишетмиләр, күрмиләр, дәшмиләр. Әдип романда бик кызыклы метаморфоза куллана. Бер кәрлә тарафыннан үтерелгән саңгырау һәм телсез музыкант Әфләтунны аның игезәк туганы Давуд табып ала, ә кешеләр күзенә күренми яши торган Нейзен Батын аның җансыз җәсадына «җан өрә».

Гомумән алганда, И. Анар инсанның дөньяга карашын дини тәгълиматлардагы кебек бербөтен итеп булмый, яшәешне аңлап бетерергә теләве аның тормышын катлауландыра гына дигән фикер үткәрә. Бөтен кешене бер системага кертергә теләү исә җәмгыятьтә канәгатьсезлек, каршылыклар, хаос тудыра. Шул сәбәпле, язучы үз әсәрләрендә аңлы рәвештә тормышны хаос итеп чагылдыра, үз укучысын «вакыйгалар каршылыгында» сакланып калырга һәм яшәргә өйрәтә. Әмма бу аның геройларының берьяклы гына яшәвенә, аңсызлык өлкәсенә нигезләнгән инстинктларга гына таянуга китерә.

Хәзерге татар һәм төрек прозасында «миф тудыру» һәм «метафизик реализм»га мөрәҗәгать итү постмодернистик әдәбиятның бер чагылышы булып тора. Татар әдәбиятында социалистик реализм агымыннан яңа фәлсәфи парадигмага – постмодернизмга борылу соңгы ике дистә ел эчендә милләтнең дәүләтле дәверенә һәм тагын да борынгырак катламнарына – ислам динен кабул иткәнгә кадәрге чорларына мөрәҗәгать итүдә күзәтелде. Татар сүз сәнгате зур һәм кыю адымнар белән мифологиягә, миф тудыруга борылды. Мифологиягә мөрәҗәгать итү татар халкының «тарихи аңы»нда сакланган архаик образларны, элементларны кабат өскә чыгаруга, аларны бүгенге укучының «исенә төшерүгә», хәтерендә кабат яңартуга ярдәм итә [55, 6–7 б.]. Татар әдәбиятында мифологиягә мөрәҗәгать итү төрек әдәбияты белән чагыштырганда, гомумән, үзгә. Мифопоэтика, фольклор образлары, үз чиратында, татар прозасында «метафизик реализм» дигән бер юнәлешне дә формалаштырды. Татар прозасында кулланылган мифологик образлар халыкның меңъеллык авыз иҗатында яшәп килгән архетипларга барып тоташа. Милли сүз сәнгатенең яңа фәлсәфи-мәдәни парадигмага күчешенә 1980 еллар уртасында язылган Ф. Бәйрәмованың «Болын» [20], «Канатсыз акчарлаклар» әсәре [21] матур дәлил булып

тора. 1990 елларда бу юнәлешне Н. Гыйматдинова, 2000 еллар башында Г. Гыйльманов һәм М. Кәбиров дәвам итә. Әлеге әдипләрнең әсәрләре миф тудыруга мөрәҗәгать итүләре, ягъни әсәрләрендә ирреаль дөнья моделен торгызулары белән татар әдәбиятында социалистик реализм иҗат методыннан аермалы булган яңача фикерләү рәвешен раслады.

Татар язучылары аңлы рәвештә генә түгел, интуитив рәвештә дә үз әсәрләрен мифологик модельгә кора, ягъни аны миф рәвешендә төзи, борынгы мотивларны алып, үзенчә үстерә, үзгәртәләр. Алар кулланган геройлар, образлар архаик фикерләүдә булмаска да мөмкин. Авторлар бары аларның тышкы формаларына охшатып үз образларын, үз мифларын тудыра. Бу аспект *миф тудыру* дип атала [55, 6–7 б.].

Немец галиме, психоаналитик К.Г. Юнг исә мифны «кешелек дөньясы тәҗрибәләрен туплаган һәм төрле чорлар өчен әһәмиятен югалмаган гаять мөһим белем» дип атый [56]. Миф ул – борынгы рухи мәдәниятне билгеләүче генә түгел, кешелек дөньясына бәяләмә бирүче система да, хәзерге сәнгатьтә әнә шушы аспектларны чагылдыручы художество алымы да. Мифопоэтикага, миф тудыруга нигезләнгән әсәрләрнең беренче уртак сыйфаты миф тудыруда; икенчесе – борынгы күзаллаулар тәэсирендә формалашкан «архетип»ларны күпләп һәм уңышлы куллануда. К. Г. Юнг яңа дәвер кешесенең күңел дөньясына тәэсир итә торган «аңсызлык өлкәсе»нә яшерелгән архетипларның (ягъни борынгы караш, образларның) тәэсири ролен фәнни яктан аңлатып бирә алды. Архетип – (грекчадан «башлангыч образ» дип тәрҗемә ителә) мәдәниятнең, аның башлангыч өлеше булган мифларның, халык иҗатының нигезендә ятучы борынгы гомумкешелек символлары [56]. Галим фикеренчә, әлеге архетиплар кешенең аңына кереп урнашкан Җир-ана образын тудыручы вак-вак образлар системасын тәшкил итәләр. «Филогенетик мөнәсәбәттә без җирнең караңгы һәм кысан тирәнлекләреннән үсеп чыгабыз. Шуның нәтиҗәсендә әлеге беркатлы, эчкерсез факторлар архетипларга әверелә, ә бу беренчел образлар, «беренче чиратта, безгә тәэсир итәләр»» (тәрҗ. – безнеке *А. Ш.*) («В филогенетическом отношении мы произрастаем из темных и тесных глубин земли. В результате этого самые непосредственные факторы превратились в архетипы, а эти первообразы «влияют на нас в первую очередь») [57, с. 133]. Бу образлар мәҗүсилек чорында аңның өске катлавында ятса, ягъни кешеләр, һәр нәрсәдә Җир һәм Күк белән бәйләнеш күреп, аларны символлар буларак кабул итсәләр, гасырлар дәвамында мәдәният үсеше алга китү сәбәпле һәм тарихи тәҗрибәләрнең кысрыклавы нәтиҗәсендә, әлеге образлар игътибар үзәгеннән төшеп калалар. Ләкин алар юкка чыкмыйлар, Юнг билгеләгәнчә, «аңсызлык өлкәсе»нә күчә баралар; яңа чор фикерләвенә яраклашып, символикалылык аша мәдәнияттә чыгыш ясыйлар. Нәтиҗәдә, бүгенге чорга килеп җиткәндә, «кешелек хәтере» дигән өлкә төрле чорларның мәдәни казанышларын, фикерләү рәвешен, дөньяны күзаллавын туплаган катлы-катлы бинаны хәтерләтә. Менә шуларны К. Юнг «коллектив аңсызлык» дигән термин белән гомумиләштерә. Аныңча, «коллектив аңсызлык» дигән өлкә һәм аның һәр күзәнәгенә тиң архетиплар дөньяны кабул итү формасына да, кешенең үз-үзен танып-белүенең тарихи-поэтик юнәлешенә дә нык йогынты ясый.

«Шул рәвешле, хәзерге татар язучылары төрки үзбилгеләнешнең тамырларын фольклор әсәрләрендә, әдәбият белән халык иҗатының бәйләнешендә эзлиләр һәм сәнгать ягыннан торгызалар» [58, 91 б.]. Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» [21], Г. Гыйльмановның «Албастылар» [16], «Оча торган кешеләр» [17], Н. Гыйматдинованың «Болан» [15], «Каракош» [59], М. Галиевнең «Нигез» [60], З. Хәкимнең «Агымсуда ни булмас» [14], М. Кабировның «Сары йортлар сере» [61], Ф. Яхинның «Сихерче кызы» [19] һ.б. әсәрләр шушы дулкында иҗат ителгәннәр. Аларның кайберләре миф тудыру ягыннан, икенчеләре исә борынгы миф-риваятьләрне яшәешнең асылын аңлату өчен үзенчәлекле куллану җәһәтеннән кыйммәтле. Барысында да интригалы сюжетка кору, мистик һәм мифологик образларны «терелтү», архаик универсалийлар төп көч булып тора. Татар әдәбиятында яңа милли аң формалаштыру бара: «Язучылар этносның традицияләрен туплаган тарихи фольклорның традицион формаларын алып, аларга яңа идеологик эчтәлек салалар» [62, 886–890 б.].

Татар һәм төрек әдәбиятларында миф тудыру, милли архетипларны ачу хосусый сыйфатларга ия. Татар әдәбиятында кеше аңының мифлар белән сугарылган катламнарына кадәр төшүдә вакыт һәм

пространство ягыннан «булганлык» сизелми; вакыйгалар да, хәтер линиясе дә эзлекле чылбырга тезелеп бара. Төрек әдәбиятында исә архетиплар постмодернизмның «перформанс» алымы ярдәмендә ачыла: Госманлы чор әдәбиятыннан сюжетларны алып, аларны «кабаттан анализлау», «күпмаскалылык», тарихны, мифларны вакыйгалар, чорлар хаосы итеп ачу омтылышы күзәтелә. Мисалга Н. Гыйматдинованың «Болан» һәм Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» һәм төрек әдәбиятыннан Орхан Памукның «Кара китап», «Минем исемем Кызыл», Әлиф Шафакның «Сөюнең Кырык таләбе» әсәрләрен китерә алабыз.

Н. Гыйматдинованың (26.10.1956 ) «Болан» [15] һәм Г. Гыйльмановның (01.02.1957) «Оча торган кешеләр» [17] мифологик фикерләү белән сугарылган повестьларында вакыйгаларның үзәген тотып торучы төп урын бар. Без аны *«вакыйга бишеге»* дип атыйбыз. Монда вакыйга үстерелгән җир – Тау хронотобы (Вакыт һәм Пространствоның үрелеше) этносның үзара тәэсирен һәм үзара бәйләнешен төшенү үзәге буларак чыгыш ясый. Мәсәлән, «Оча торган кешеләр» әсәрендә Кала-тау серле урын гына түгел, ә рухи кичерешләрнең, җан сафлыгының чишмә башы булган һәм аларны Илаһият белән бәйләп торучы хронотоп та. Хуҗалар тавы да - җаннарның сафлыгын саклап торучы, табигать-җирнең язмышы өчен җаваплы урын. Сихерче кызы яши торган утар исә төп геройның рухи хәтерендә Җиһан белән бәйле әдәби-сәнгати мирасны яңартучы, шуның аша малайның җанын сафландыручы урын булып тора.

Әдәби әсәрдәге бу урыннар үзенчәлекле маргиналь зоналар буларак кабул ителәләр. Җир кешеләренең хронотопларның асылына төшенә алмавы, шуңа күрә аларга тискәре караш урнашуы; сихер, явызлык, убыр урыны дип аталуы күрсәтелә. Әмма әсәрләрнең ахырында бу оппозицион каршылык кешеләрнең дә, әлеге маргиналь зоналарның да асылын ачарга ярдәм итә. Үзләрен дөрес юлда, гадел гамәлдә, изге нияттә дип уйлаган кешеләр изгелек, рух, илаһият белән бәйләнештә торган һәм аларның җаннарын саклап торучы маргиналь урыннар белән чагыштырганда, явыз, начар булып чыгалар [63, 11–19 б.]. Әсәрләр мәҗүсилек катыш метафизик реализм алымы белән язылган, чөнки аларның үзәгенә тәңречелек белән бәйле образ-мотивлар (болан, Хуҗалар тавы, Кала-тау, рухлар) урнаштырылган. Шуның белән бергә һәр ике әсәрдә дә дөньяның үзәге итеп тау образын, тудыручы итеп Тәңрене-Ходайны атыйлар.

«Болан», «Оча торган кешеләр» повестьларында кулланыла торган Тау поэтик образы төрле халыкларның мифологиясендә чагылыш тапкан. Борынгы төркиләрдә Тау образы изге (сакраль) җир буларак кабул ителгән һәм ул Җир-Су культының бер өлешен тәшкил иткән. Әлеге образга нинди мәгънә салынган соң? Галимнәр фикеренчә, мифологиядә Тау галәм моделен чагылдыручы образ, дөньяның үзәге булып санала [45]. Галәм күчәре менә шушы тау аша үтеп, югарыга таба дәвам итә һәм Казык йолдызның урынын күрсәтә. Тауның аскы өлеше җир асты дөньясын фаразлаган. Мондый тау өч дәрәҗәле итеп күзалланган. Тауның башы – Аллалар урыны, уртада – Җирдә – адәм балалары яши, тауның астына төрле рухлар хуҗа. Мондый бүленеш Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» әсәрендә чагылыш тапкан. Тауның эчендәге мәгарәнең түбәсенә дә Җир белән Космосны бәйләп торучы Чулпан йолдыз ясалган. Язмышлары Чулпан йолдызы белән бәйләнгән Сәүбән, аның әтисе, улы һәм Сәвия Тауны Тәңре-Алланың тәхете буларак кабул итәләр. Кала-тауның ел саен бер мәртәбә «кәефсезләнеп» алуы, аннан ят, сәер тавышлар ишетелү аның эчендә рухлар барлыгын раслый сыман. Мифларда тауның куышы булу әйтелә. Кала-тауның да куышы сурәтләнә, аның аша өлкән Сәүбән дә, аның улы да икенче дөньяга – серләр дөньясына керә. Бу бәйләнешнең асылын эзләү әсәрнең буеннан-буена сузыла һәм ул бары ахырда гына ачыла. Нәкъ менә җаннары Илаһият белән бәйле затларга гына тауның яшерен куышы билгеле булуы ачыклана [64, 90–92 б.].

Дөньяның асылын аңлату ягыннан Ф. Яхинның (02.01.1961) «Сихерче кызы» повесте [19] кызыклы. Аның әсәре төрле чорларга мөнәсәбәтле мифологик, әдәби фикерләрне герой һәм укучы хәтерендә кабат яңарту ягыннан әһәмиятле. «Сихерче кызы» повестенда XX гасыр башы татар шагыйре Г. Тукайның әсәрләреннән өзекләр-цитаталар, экиятләр, риваятьләр, мифологик мотивлар да китерелә, экиятләрдә сурәтләнгән геройлар халәтенә якын аллюзияләр, реминисценцияләр дә кулланыла. Әдәбият белеме фәнендә бу күренешне җыйнап кына «цитацияләр» дип атыйлар. Рус галиме М. Бахтин, француз галимнәре Жан-Жак Деррида, Ролан Барт,

Юлия Кристевалар яңа дәвер кешесенең хәтерен әнә шундый цитаталардан «тукылган» «текст» итеп карыйлар. Әсәр эчтәлегендә төрле «тарихи-мәдәни чорларны “яңарту”га мөрәҗәгать итү әлеге әсәрнең постмодернистик рухта язылуын» дәлилли [40, 237–243 б.].

«Сихерче кызы» повестенда борынгы «Мөхәммәдия», «Бакырган» китаплары стилендәге хикәяләү алымы ачык сиземләнә. Ләкин шул ук вакытта бүгенге көннән торып бала чагына «кайтучы» автор образы да тоемлана. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар авылга кунакка кайткан малай образы аша гәүдәләндерелсә, әлеге вакыйгаларга мөнәсәбәт өлкән шәхес – автор шәхесе позициясеннән белдерелә, чөнки яшь малай вакыт-вакыт өлкәннәрчә фикер йөртә башлый.

Ф. Яхин «Сихерче кызы» повестенда халык әкиятләрендә сакланып калган диюләр, су анасы, шайтаннар, шүрәлеләр хакындагы сюжетларны әкияти чорга куеп, әмма бүгенге көн кешеләренең фикерләү рәвешенә якынайтып сурәтли. Бу «әкият»ләр әсәрдә фрагментлар рәвешендә кулланылган. Фрагментлар бергә җыелып, әсәрдә чагылыш тапкан фәлсәфи концепцияне ачыкларга ярдәм итә. Димәк, әкият-мифлар әсәрнең мавыктыргыч булуын да, фәлсәфи ягын да тәэмин итә.

Миф тудыру ягыннан төрек әдәбиятында Орхан Памук (Orhan Pamuk, 07.06.1952) әсәрләре игътибарга лаек. Аның «Кара китап» («Kara kitab») [26] һәм «Минем исемем – Кызыл» («Benim adim Karmizi») [27] дигән романнары бу ноктадан кызыклы. «Кара китап» («Kara kitab») постмодернистик мемуар прозасы кысаларында автобиографик роман буларак иҗат ителгән, аның ике дәрәҗәдәге укылышы бар. «Ике дәрәҗә»гә ия булу, «берничә катлылык» әсәрнең структурасында да еш күзәтелә. Мәсәлән, төп геройлар Галип белән Җәләл образларында, башка персонажларны ачуда да чагыла. Төп геройның Истанбул буйлап сөйгәнен эзләве Урта гасыр госманлы әдәбиятында еш кулланылган мистик трактатларны хәтерләтә: каһарман юл дәвамында төрле кызыклы, сәер хәлләргә очрый, аларда үзенең рухи сыйфатларын көчәйтә. Бу – әсәрнең беренче дәрәҗәсендә аңлашылган фәлсәфә. Икенче дәрәҗәдә герой тарган вакыйгалар, хатирәләр суфичылык әдәбияты мотивларын «яңарта» һәм Җаннның Тудыручыны эзләве белән тәңгәл карала ала. Бу исә кешенең үз-үзенә кайтуы, үз асылын табуы белән чагыштырыла.

«Кара китап»- чит ил укучысы өчен төрек мәдәниятенең бишеге булган Истанбул шәһәрен ачу ягыннан бик матур коллаж-тасвирларга нигезләнгән роман. О. Памук герой хәтерендә иске Истанбулның төрле мәхәлләләрен (бистәләрен) яңарта. Бу хатирәләрне кертүнең максаты – төрек кешесенең этномәдәни үзбилгеләнешен ачу; аларның Көнбатыш мәдәнияте вәкиле була алмавын күрсәтү, шул ук вакытта төрки-мөселман традицияләрен югалтуын ачыклау [47, 8 б.]. Язучы фикеренчә, төрекләр шушы ике милли-мәдәни парадигма эчендә «бикләнеп калган». Көнбатыш мәдәнияте элементларын алу төрки мәдәниятне югалтуга илтә; милләт чит мәдәниятнең копиясе, «симулякры» рәвешен ала, үз йөзен югалта, дип саный Куршад Эртугрул [65, 104 б.]. Бу исә кешеләрнең эчке-рухи фаҗигасенә китерә: ялгызлык, бәхетсезлек тойгысы көчәя.

«Кара китап» романының тексты интертекстуальлек белән сугарылган. Әсәрдә Көнбатыш мәдәниятенең һәм мөселман язучыларының, философларының әсәрләренә мөрәҗәгатьләр, цитаталар китерелә. Романда, әле XX гасыр ахырында ук кешеләр аңына тәэсир итү өчен, кино индустриясе тудыру хакында фикерләр кузгатыла, тамашачыны тормышның «симулякры» (ялган копиясе) булган кинофильмнар аша ялган дөньяга алып кереп китү куркынычы ассызыклана.

Әлеге хезмәтне язганда, О. Памукның «Кара китап» әсәрендә төрек халкының милли традицияләрен барлавы (чәй пешерү, урамда өлкәннәрнең аралашу ысулларын яратып искә төшерү, балачак хатирәләрен сагынып яд итү һ.б.) татар язучысы Мөхәммәд Мәһдиевнең (01.12.1930 – 14.06.1995) «Бәхилләшү» [18] әсәрен хәтерләтте. Әдипнең әлеге повесте да – постмодернистик рухта иҗат ителгән тәүге әсәрләрнең берсе. Язучы повестьта, демонстратив рәвештә диярлек, социалистик реализм агымыннан, аның әсәрнең поэтикасына куелган таләпләреннән, характерларны һәм вакыйгаларны сурәтләүдәге сәбәп-нәтиҗә бәйләнешеннән, ягъни әсәрне бер сюжетка корудан читкә китә. Вакыйгалар да монда бер-бер артлы, хронологик тәртиптә бирелми, «алар күчеп йөри» [66, 34 б. ]. Нәтиҗәдә, язучының әсәрләрендә сюжет үзенең традицион ролен югалта, аның вазифасын бүлекләрнең лейтмотивлары башкара, хикәяләү фрагментарь рәвештә бара. Бүлекләрне исә үз чиратында, ассоциатив моментлар, бүлек ахырларында

бирелгән автор фикерләре-нәтиҗәләр һәм дә автор образы үзе бәйләп тора. Укучы алдында, башка язучылар әсәрләрендәге кебек, бер вакыйганың үстерелеше түгел, ә чынбарлыкның өзек-өзек һәм төрле чордагы төрле вакыйгалары пәйда була. Шул сәбәпле тормыш ул калейдоскоп кебек гел үзгәрүчән дигән фикер туа [67, 107–115 б.]. Композициянең төзек түгеллеге, тәмамланмаганлыгы, эпизодлар рәвешендә булуы, төп фикернең әйтеп бетерелмәве язучы тарафыннан махсус сайланылган, чөнки чынбарлыкның өзек-өзек кисәкләре, беренчедән, хәтер киштәләрен берәм-берәм актаруга ишарә, икенчедән, ул тормышның да әнә шулай төзек түгеллеген, татар авылының гына түгел, татар характерының үзгәрүен, катлаулануын, татар кешесендә эчке бер ныклы үзәкнең булмавын күрсәтә. Тормыш-чынбарлыктагы вакыйгаларның агышын читтән карап торучы автор образы язучыны канәгатьләндерми, ул үзе үк әсәрнең, ягъни үзе тудырган дөньяның эченә кереп китә, анда катнаша. «Бәхилләшү» повестенда хикәяләүче авторның аңы, – хикәяләүне, вакыйгаларны бәян итүне оештыру алымы гына түгел, ә нәкъ менә язучының этик һәм әхлакый позициясе ачык чагылган идеологик үзәк тә.

О. Памук «Кара китап» романында игътибарны аеруча «Йорт» символына юнәлтә. Йорт, аның фикеренчә, гаиләне тотып тора торган иң төп символларның берсе. Язучы өчен инсан дөньясының җимерелүе постмодернистик хаос – йорттан, гаиләдән качудан башлана. Бу исә милли аңның, үзбилгеләнешнең югалуына китерә. Нәк шушы идея М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повестенда да чагылыш таба. Әдәби әсәр юкка гына «Бәхилләшү» дип аталмаган. Монда язучы үзенең яшьлеге, сабый чагы узган, әтисе-әнисе яшәгән авыл белән дә, татар халкының гореф-гадәтләре (мәсәлән, ипи салу, печән чабу), татар кешесенә генә хас сыйфатлар (җор теллелек, сабырлык, баланы милли мәдәниятҡә нигезләнгән алымнар белән тәрбияләү, үз туган җиреңне ярату, табигатьне ярату, хөрмәт итү, өлкәнне санлау, кечеләргә ярдәм итү кебек сыйфатлар) белән дә хушлаша [68, 88-89 б.].

О. Памукның «Минем исемем – Кызыл» («Benim adim Karmizi») [27] дигән икенче бер романы шулай ук үзенең поэтикасы белән аерылып тора. Ул шәрык әдәбиятында ярaтып кулланыла торган «кысалы кыйсса» алымына нигезләнә: детектив сюжетка корылган әсәр өзек-өзек вакыйгалар җыелмасыннан тору тәэсирен калдыра. Ачылмаган сер, ачык калган финал, үзен ялгыш кына фаш иткән җинаятьче кебек детектив әсәре атрибутларына нигезләнгән романда, язучы «автор маскасы»ның барлык төрләрен дә диярлек куллана. Әсәрнең төрле тарихи һәм мәдәни дәрәҗәсе Көнбатыш һәм Көнчыгыш мәдәниятләренең сәнгати-эстетик кануннарындагы үзгәлекне күрсәтә һәм ача. Эстетик яктан югары сәнгать әсәре булып саналган, серләренә төшенү өчен, дистә елларны багышларга туры килгән «шәрык миниатюрасы» һәм «хөсни хат» (гарәп каллиграфиясе) кебек жанрларны әсәрнең үзәк темасы итеп алу О. Памукка яшәешкә, дөньяга карашларны ачарга мөмкинлек тудыра. Язучы бүгенге төрекләрдә үтә нечкә сиземләүгә ия булган чиста рухи талантның бетә баруын ассызыклый, бу исә аларның дөньяга карашы үзгәрүгә дәлил икәнен күрсәтә. Монда әдип төрекләрнең үзбилгеләнеше мәсьәләсенә тагын бер кат туктала. Шул ук вакытта илаһи сафлыкның дәлиле булып торган әлеге сәнгать дөньясында да, Ю. Кристева билгеләгәнчә, «төрле интригалар, үтерешләр булуны күрсәтә»: яшәешнең һәм кешеләрнең фанилыгын ача, тормышның «күпдәрәҗәле» икәненә басым ясый (Кара: [40, 237 б.]). Әсәрдә ислам дине кануннарына нигезләнгән вәгазьчеләрнең ялган мотивларга, архетипларга ияреп, хакыйкатьтән читкә китүе дә искәртелә.

Татар һәм төрек әдәбиятларында метафизик реализм кысаларында язылган әсәрләр дә бар. Мондый төр әсәрләр Яшәешнең метафизик дәрәҗәсен ачуны үзмаксат итеп куя; рухи эзләнүләрне нигез итеп алып, кеше күңеленең яшерен катламнарын, дөнья яратылышының серле, билгесез якларын үзенчәлекле итеп сурәтли. «Метафизик реализм» татар әдәбиятында үзенчәлекле алым булып тора. Нигезе булып реализм калса да, аңа «яшерен дөнья», «яшерен чынбарлык», «хакыйкый чынбарлык» дигән параллельләр өстәлә. Татар әдәбиятында бу юнәлешкә Ф. Бәйрәмова, М. Галиев, М. Кәбиров, З. Мәхмүди иҗатларыннан аерым әсәрләрне мисалга китерергә мөмкин. Алар Кеше һәм җәмгыять арасындагы мәңгелек көрәш яктылыгында Адәм баласының асылын фәлсәфи яктыртуга нигезләнә. Адәм баласының яшәеше хакындагы фәлсәфә ул.

Ф. Бәйрәмованың (05.12.1950) бер төркем әсәрләрендә бу мәсьәлә, кешенең эчке дөньясы аша үткәрелеп, җан, күңел кичерешләре белән

тыгыз, тирән бәйләнештә бирелә. Кеше ниндидер котылгысызлыктан гына торган Язмыш алдында ялгызы кала. Тагын бер кызыклы моментка игътибар итәргә кирәк: әдибә хыял, хис-кичереш дөньясыннан гына торган Инсанны Җир тормышы белән бәрелештерә. Һәм, нәтиҗәдә, үзен аңлаган, яраткан якын дуссыз, җан кардәшсез кешегә бу дөньяда яшәүнең гаять авыр булуын, хәтта мәгънәсе юклыгын ассызыклый.

Ф. Бәйрәмова татар әдәбиятында постмодернистик парадигмалар кысаларында язылган әсәрләрнең берсе саналган «Канатсыз акчарлаклар» повестенда «тән» һәм «җан»ны ике аерым мөстәкыйль дөнья итеп карый, аларның барлыкка килү «тарихы»на күзәтү ясый [21]. Әсәрдә Ак маңгайның Җир тормышы түгел, җаны «уяна» торган ирреаль дөнья күбрәк яктыртыла. Автор гүя реаль тормыш авырлыкларыннан, вакыйгаларыннан махсус «читкә тайпыла». Җир кешеләре белән Күктән төшүчеләр турында чагыштырулар аша Ф. Бәйрәмова эстетик детальләргә дә игътибар юнәлтә. Аныңча, Җирдә ике төрле бәндә яши, әмма очрашсалар-кавышсалар да, яшәү максатлары, теләк-омтылышлары капма-каршы булу сәбәпле, алар бер-берсен тулысынча аңлый алмый. Әсәрләрдәге төп идея дә шуннан килеп чыга: Кеше – тән һәм рух берлеге, Җирдә ул бәхеткә бары тик акыл белән Җан берлеге, ягъни рух аша гына, Илаһияткә-Аллаһка инанып яшәгәндә, Тудыручыбыз билгеләгән юл белән тормыш иткәндә генә ирешә ала [69, 31–32 б.].

Метафизик реализм агымы төрек язучысы Әлиф Шафак (25.10.1971) иҗатында да матур чагылыш таба. Аның «Илаһи мәхәббәт» («Aşk») [28], «Остазым» («Ustam ve Ben») [29] кебек әсәрләрендә төрек этносының формалашуына, төрек кешесенең төрле чорларда яшәү рәвешенә бәйле архетипик проблемалар калку яктыртыла. Әсәрләрдә тормышны дидактик фикерләрне барлап бару аша салмак кына «өйрәнү» – язучының отышлы үзенчәлеге. Язучының «Илаһи мәхәббәт» («Aşk») әсәренең фәлсәфи җирлеген демифологизация (таркатучы) һәм ремифологизация (тудыручы) каршылыгына корылган постмодернистик алым билгели. Әсәрнең төп геройлары – Җәлалетдин Руми һәм Шәмсетдин Тәбризи. Ш. Тәбризинең шагыйрь Румига язган кырык хатын әсәрнең нигезенә салып, Ә. Шафак төрек милли тарихының күнегелгән дини тәгълиматын (дискурсын) җимерә һәм аның урынына, Тәбризинең Яшәеш, аның асылы хакындагы сүзләрен үзәккә куеп, яңа бер караш-метанарратив формалаштыра. Бер шәлкем төрек галимнәре бу әсәрдән тарихи дөреслек эзли. Алар, Тәбризи һәм Руми арасында булган серле-сәер мөнәсәбәтләрне гади роман итеп кенә ачуга каршы чыгып, әсәрдә тарихи фактлар юк дигән нәтиҗә ясыйлар. Әмма аның постмодернистик парадигма кысаларында язылуын аңлаган укучыга да, әдәбият белгечләренә дә әлеге әсәрдә, метафизик реализмга нигезләнеп, бу ике бөек шәхес хакында яңа «миф» тудырылу күренеп тора. «Илаһи мәхәббәт» («Aşk») әсәрендә Ә. Шафак «инану», «акыл» кебек төшенчәләрнең эчтәлеген ача; алар артында һәрвакыт төрек кешеләрен ялгыш юлга, хаоска, үлемгә, аңсыз гамәлләргә этәрә торган кара көчләр булуына басым ясый. Әсәр берничә дәрәҗәгә ия. Беренчесендә Тәбризи-Руми мөнәсәбәтләрен, чорның атмосферасын тасвирлау бирелсә, икенче дәрәҗәдә – төрек милләте һәм Яшәеше. Язучы карашынча, төрек кешесе үз милли йөзен, милли үзбилгеләнешен югалтмаска тиеш; моның өчен Руми һәм Тәбризи кебек бөек шәхесләрнең фәлсәфәләренә таянырга кирәк. Әсәрдәге хаос концепциясе И. Анар һәм О. Памук әсәрләрендәге «хаос»тан аерыла: вакыйгалар «нарратив» формасында өзек-өзек итеп тасвирланса да, «үткән-бүген-киләчәк» билгеле бер вакыт сызыгына утыртылган. Монда, киресенчә, хаостан качу күренә: хаостан качу адәм баласын Инсан дигән затның симулякры (ялган копиясе) булудан саклап кала ала, Хакыйкать белән кушылу үз асылыңа кайтуга китерә. Әлиф Шафак Тәбризинең киңәшләре аша, системалы яшәү, Хакыйкатьтән килгән «Сүз»нең («логос»ның ) асылын аңлау гына хаостан качу һәм аннан котылу чарасы икәнен ачыклый.

**Нәтиҗәләр**

1. Татар һәм төрек әдәбиятларында постмодернистик тенденцияләр язучыларның әсәрләрендә эчтәлек дәрәҗәсендә, хикәяләү рәвешендә чагыла: постмодернизмның күптөрле алымнары һәм мотивлары отышлы кулланыла. Ике тугандаш сүз сәнгатендә постмодернистик фәлсәфәгә таянуда охшаш яклар күзәтелсә дә, милли мәдәниятләрнең нигезендә ята торган милли архетипларның, язучыларның дөньяга, яшәешкә карашларының үзгәлеге әсәрләрдә кулланыла торган

постмодернистик алымнарның төрлелегенә дә китерә.

2. Һәр ике әдәбиятта да язучылар сюжетны сайлауда, тарихи, мәдәни вакыйгаларны торгызуда милли мәдәни-тарихи дискурслар кысаларыннан читкә чыкмыйлар. Шуңа да аларда постмодернизмның Көнбатыш әдәбиятларыннан аерылып торган, үз йөзе, үз милли варианты формалаша. Мәкаләдә шәрехләнгән язучылар иҗаты һәм аларның әсәрләре постмодернистик парадигма кысаларына сыя торган, үзенчәлекле өйрәнү методларын, ысулларын да таләп итә. Хезмәттә кулланылган яңа фәлсәфи терминнар үзләренең уңышлы булуын дәлилләде.

3. Татар язучыларының постмодернистик әсәрләрендә мифологик катламга, миф тудыруга, төрки, милли архетипларга игътибар итү көчле. Мифологиягә мөрәҗәгать итү язучыларга татар халкының «тарихи аңы»нда сакланган архаик образларны, элементларны беренче планга чыгаруга, аларны бүгенге укучының «исенә төшерүгә», хәтерендә кабат яңартуга ярдәм итә.

4. Татар әдипләренең миф тудыруга мөрәҗәгать итүләре, ягъни әсәрләрендә ирреаль дөнья моделен торгызулары ике яклы, ике планда бара. Әсәрләрнең барысында да интригалы сюжетка кору, мистик һәм мифологик образларны «терелтү», кертеп җибәрү, архаик универсалийлар төп сыйфат булып тора. Тышкы яктан караганда язучы аңлы рәвештә үз әсәрен архаиклаштыра, ягъни әсәрен борынгы риваятьләр рухында, борынгылаштырып сурәтли, архаик-борынгы образларны, сюжет элементларын, мотивларны куллана. Тарих та, вакыйгалар да, күп очракта, эзлеклелек принцибына нигезләнә. Әмма аллюзия, реминисценция кебек алымнар аша әсәр җирлегенә борынгы мифлар, узган чорлардагы әдәби әсәрләрдән, халык иҗатыннан «өстәмәләр» килеп керә. Шул рәвешле төрле чорлар, төрле чынбарлыклардан коллаж ясала.

5. И. Анар, О. Памук, А. Шафак кебек төрек язучыларының әсәрләре, нигездә, төрек тарихында «вакланган», «кечкенә» кешенең яшәешен тасвирлау, төрек милләтенең үзбилгеләнешен югалту проблемасы белән тыгыз бәйләнгән. Тарихка пародия, ирония күзлегеннән якын килеп, алар инсан яшәешенең яңа кыйммәтләрен барлый, хаос рәвешендә оешкан җәмгыятьтә адәм баласының исән калу юлларын эзли.

6. И. Анар һәм О. Памук әсәрләрендә тарихи вакыйгалар, чылбыр булудан туктап, «нарратив» / «текст» рәвешен ала. Нәкъ менә «нарратив» сыйфаты тарихны төрле якка юнәлтелгән вакыйгалар тупланмасы итеп карарга ярдәм итә. Төрек язучылары өчен тарихи процесс, «үткән-бүген-киләчәк» туры сызыклы агым түгел, ә очраклы, кинәттән туган вакыйгалар өстенлек итә торган хаос тулы дөнья, шуңа да очраклылык аеруча игътибарга лаек, дип санала.

7. Төрек әдәбиятында постмодернизмның үзенчәлекле билгесе буларак, И. Анар иҗатында формалашкан тарихи-фәлсәфи (историософик) романны күрсәтергә кирәк. Аның поэтикасы гадәти тарихи романнардан аерыла: әсәрнең сюжеты һәм фабуласы тарихи үткәндә булган вакыйгаларга аллюзия итеп кенә карала, тарихи вакыйгалар факт итеп алынмый. Нәкъ менә шушы күренеш төрек әдәби тәнкыйтендә О. Памук, Ә. Шафак әсәрләре тирәсендә бәхәсләр уятуга китерә. Бер төркем галимнәр төрек социумының һәм этносының формалашуын тасвирлаган, архетипик образларга нигезләнгән әсәрләрне, аларның постмодернистик поэтикага нигезләнеп язылуларына игътибар итмәү сәбәпле, тарихи дөреслекне күрсәтмәүдә гаеплиләр. Бу әсәрләрдә тарихи вакыйгалар кысаларына утыртылып, билгеле тарихи шәхесләр язмышын сурәтләү максат итеп куелмый, киресенчә диалоглар, монологлар «Төркия язмышы», «Төркия һәм Көнбатыш каршылыгы», «дәүләт тарихы һәм дөньяның бетүе», «төрекләрнең тарихи яшәү мәгънәсе» кебек аерым концептларны ачуга йөз тота.

8. Әлеге хезмәт төрек һәм татар әдәбиятларында чагылыш тапкан постмодернистик әсәрләргә күзәтү формасында башкарылды. Бер мәкалә кысаларында ике әдәбиятның үзенчәлекле әсәрләрен, авторларын яктырту мөмкин түгел. Шул сәбәпле башка язучыларның иҗатлары, шулай ук фәнни мәкаләнең өйрәнү объекты булган әдипләрнең әсәрләре дә тагын да тулырак, тирәнрәк анализлауны таләп итә. Мәкаләдә бирелгән нәтиҗәләр татар һәм төрек әдәбиятларында постмодернистик парадигманы аңлауда ярдәмче була алалар.

## Йомгак

Хезмәттә шәрехләнгән, яңа сурәтләү теле белән язылган татар һәм төрек телендәге әсәрләрдә дөньяның бербөтен булмавы,

конкрет бер сурәтләү алымы ярдәмендә генә чынбарлыкны тасвирлау мөмкин түгеллеге ачык чагыла. Бу ике төрки әдәбиятта да кешенең урыны, билгеләнеше, яшәү максаты һ.б. турында яңа фәлсәфи-эстетик, иҗтимагый-мәдәни концепцияләр тууы турында сөйли һәм дөньяны кабул итүнең, күзаллауның һәм аны сәнгатьчә чагылдыруның постмодернистик парадигмага нигезләнгән яңа формасы булып тора.

**Әдәбият**

1. *Нигматуллина Ю.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. Казань, 2002. 176 с.

2. *Заһидуллина З.* Модернизм һәм XX гасыр башы татар прозасы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. 207 б.

3. *Шамсутова А.* Татар әдәбиятында постмодернистик концепцияләрнең чагылышы. Махсус курс өчен кулланма. Казан: Казан дәүләт гуманитар институты, 2003. 36 б.

4. *Gümüş S.* Modernizm ve Postmodernizm. İstanbul: Can Yayınları, 2021.152 s.

5. *Ecevit Y.* Türk Romanında Postmodernist Açılımlar. İstanbul: Everest Yayınları. 2021. 247 s.

6. *Emre İ.* Postmodernizm ve Edebiyat. Ankara: Anı Yayınları, 2006. 380 s.

7. *Akay A.* Postmodernizmin ABC'si. İstanbul: Say Yayınları, 2010, 175 s.

8. *Aydın H.* Eleştirel Aklın Işığında Postmodernizm ve Yansımaları. Bursa: Sentez Yayınları, 2021. 312 s.

9. *Bingöl U.* Dijital Çağda Pusulası Bozulan Şiir – Postmodernizm ve Şiir Üzerine. İstanbul: DBY Yayınları, 2021. 312 s.

10. *Evis A.* Türk Romanında Postmodernizm – Teori ve İnceleme. İstanbul: Kriter Yayınları. 2021. 340 s.

11. *Koçakoğlu B.* Anlamsızlığın Anlamı Postmodernizm. Ankara: Hece Yayınları, 2012. 200 s.

12. *Шамсутова А.* Татар әдәбиятында постмодернистик карашлар // Гыйльми язмалар, ТГГИ. Гуманитария. 2002. Октябрь. Б. 45–49 б.

13. *Хәким З.* Сайланма әсәрләр. 3 томда. Т. 1: роман. Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. 399 б.

14. *Хәким З.* Агымсуда ни булмас. Сатирик роман // Хәким З. Сайланма әсәрләр. 3 томда. Т. 2: повестьлар һәм хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 247 б.

15. *Гыйматдинова Н.* Болан // Гыйматдинова Н. Кыргый: повестьлар һәм хикәяләр. Казан: Татар.кит.нәшр.,1996. 142 б.

16. *Гыйльманов Г.* Албастылар: Роман. Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. 403 б.

17. *Гыйльманов Г.* Оча торган кешеләр: роман, повестьлар, бәяннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 463 б.

18. *Мәһдиев М.С.* Сайланма әсәрләр. Биш томда. 4 т.: Повесть, роман, юльязмалар. Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. 480 б.

19. *Яхин Ф.* Ак әбиләр догасы: хикәяләр, повестьлар. Казан: Татар.кит.нәшр.,2000. 255 б.

20. *Бәйрәмова Ф.* Болын // Фәйрәмова Ф. Моң: повестьлар. Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. 272 б.

21. *Бәйрәмова Ф.* Канатсыз акчарлаклар // Фәйрәмова Ф. Күңел карлыгачларым: повестьлар. Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. 272 б.

22. *Anar I. O.* Puslu Kitalar Atlasi. Istanbul. İletişim Yayıncılık – Çağdaş Türkçe Edebiyat Dizisi, 1995. 238 s.

23. *Anar I.O.* Efräsiyäb'm Hikäyeleri. Istanbul. İletişim Yayıncılık, 1998.245 s.

24. *Anar I.O.* Kitab-ül Hiyel. Istanbul. İletişim Yayıncılık, 2011. 144s.

25. *Anar I.O.* Suskunlar. Istanbul. İletişim Yayıncılık, 2007. 268 s.

26. *Pamuk O.* Kara Kitap. Türkiye İletişim Yayınları, 2000. 552 s.

27. *Pamuk O.* Benim Adım Kırmızı. Yapı Kredi Yayınları, 2013. 552 s.

28. *Şafak E.* Aşk. Istanbul: Doğan Kitap, 2009. 420 s.

29. *Şafak E.* Ustam ve Ben. Istanbul: Doğan Kitap, 2013. 480 s.

30. *Барт Р.* Три внешних пространства. Раскол. Выход из тупика. Избранные работы: Семиотика. Поэтика: Пер. с фр. / Сост., общ. ред. и вступ. ст. Г. К. Косикова. М.: Издательская группа «Прогресс», «Универс», 1994. 616 с.

*31. Бодрийяр Ж.* Символический обмен и смерть. М.: Добросвет, КДУ, 2006. 389 с.

32. *Лиотар Ж.-Ф.* Состояние постмодерна / Пер. с фр. М.: Институт экспериментальной социологии; СПб.: Алетейя, 1998. 160 с.

33. *Ортега-и-Гассет Х.* Дегуманизация искусства // Ортега-и-Гассет Х. Эстетика. Философия культур. М., 1991. 588 с.

34. *Фуко М.* Слова и вещи. Археология гуманитарных наук. СПб.: A-cad, 1994. 406 с.

35. *Хайдерггер М.* Время картины мира // Хайдерггер М. Время и бытие. М. Республика, 1993. 447 с.

36. *Хейзинга Й.* Игра и культура // Хейзинга Й. Homo Ludens. Статьи по истории культуры. М., 1997. 416 с.

37. *Ильин И.* Театр как критика. Маска автора. Общество спектакля // Ильин И. Постмодернизм от истоков до наших дней. М.: Интрада, 1998. 255 с.

38. *Маньковская Н. Б.* Эстетика постмодернизма. СПб.: Алетейя, 2000. 347 с.

39. *Скоропанова И.С.* Русская постмодернистская литература: новая философия, новый язык. СПб.: Невский Простор, 2001. 416 с.

40. *Çeler Z.* Julia Kristeva ve İçimizdeki Yabancı // DoğuBatı Dergisi. 2021. S. 56. S. 237-243.

41. *Бахтин М. М.* Эпос и роман. СПб.: Азбука, 2000. 304 с.

42. *Лотман Ю.* Заметки о структуре текста. Культура и текст как генераторы смысла // Лотман Ю. История и типология русской культуры. СПб., 2002. 768 с.

43. *Тюпа В.И.* Нарратология как аналитика повествовательного дискурса (Архиерей А.П. Чехова). Тверь: Твер. гос. ун-т, 2001. 58. с.

44. *Тюпа В. И.* Художественный дискурс: (введение в теорию литературы). Тверь: Твер. гос. ун-т, 2002. 80 с.

45. *Топоров В.* Миф. Ритуал. Символ. Образ. Исследования в области мифопоэтического. Избранное. М.: Издательская группа «Прогресс» — «Культура», 1995. 624 с.

46. *Репенкова М. М.* Вращающиеся зеркала. Постмодернизм в литературе Турции. М.: Восточная литература, 2010. 240 с.

47. *Сулейманова А.С.* Постмодернизм в современном турецком романе: дис. … канд. филол. наук. 10 01 03 - Литература народов стран зарубежья (литературы стран Азии и Африки). Санкт-Петербург, 2007. 216 с.

48. *Карева О. В.* Постмодернистская парадигма в романистике Ихсана Октая Анара: автореф. дис. … канд. филол. наук. 10.01.03 Литература народов стран зарубежья (литературы азиатского региона). Москва, 2012. 28 с.

49. *Шамсутова А.* Хәзерге татар әдәбиятында постмодернистик карашлар һәм Зөлфәт Хәким иҗаты // Гыйльми язмалар. ТГГИ, 2003. № 11. Б. 17–21.

50. *Gündüz O.* İhsan Oktay Anar'ın Kurgu Dünyası/Anar'ın Kurgu Evreninde Postmodern Bir Gezinti. Ankara: Grafiker Yayınları, 2012. 254 s.

51. *Бреева Т.Н.* Национальный миф в русском историософском романе рубежа XX XXI веков. Казань: Казанский гос.ун-т, 2010. 270 с.

52. *Кристева Ю.* Избранные труды: Разрушение поэтики / Пер. с франц. М.: «Российская политическая энциклопедия» (РОССПЭН), 2004. 656 с.

53. *Tekin M.* Roman Sanatı 1- Romanın Unsurları. İstanbul: Ötüken Neşriyat, 2017. 324 s.

54. *Descartes R* . Yöntem Üzerine Konuşma. İstanbul: Dogu Bati Yayınları, 2018.92 s.

55. *Шамсутова А.* Хәзерге татар прозасында миф тудыру // Шамсутова А. Хәзерге татар прозасы. Икенче җыентык. Мәктәп укучылары өчен хрестоматик дәреслек. Казан: Татарстан республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2005. 479 б.

56. *Юнг К.* Архетип и символ. Москва: Renessans, 1991. 343 с.

57. *Юнг К.* Проблемы души нашего времени. М.:Progress, Univers, 1994. 336 с.

58. *Шамсутова А., Каримова Р.* Мифологизм и фольклорные мотивы в современном татарском романе // Сборник материалов Всероссийской научно-практической конференция «Роман в литературе и культуре народов России». Восточно-Сибирский государственный институт культуры (г. Улан-Удэ, 19–21 мая 2021года). Улан-Удэ, 2021. С. 85–99.

59. *Гыйматдинова Н.* Сихерче: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 286 б.

60. *Галиев М.* Нигез: повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 367 б.

61. *Кәбиров М.* Мәхәббәт яңгыры: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 431 б.

62. *Karimova R.* Tatar Mitolojisinde İyeler. The Familier Spirits in Tatar Mythology // Gaziantep University Journal of Social Sciences. 2016. S. 15(3) S. 881–897.

63. *Шамсутова А.* Нәбирә Гыйматдинова иҗатында мифологик катлам («Болан» әсәре мисалында) // Милли мәдәният. 2006. № 9. Б. 11–19 б.

64. *Шамсутова А.* Җан сурәте: язучы Галимҗан Гыйльманов иҗатына штрихлар // Мәйдан. 2007. № 4. Б. 87–103.

65. *Ertuğrul K.* Türkiye Modernleşmesinde Toplumsal ve Bireysel Özerklik Sorunu: Oğuz Atay ve Orhan Pamuk'la Birlikte Düşünmek / /Doğu Batı Dergisi. 2003. S. 22. S. 91–105.

66. *Закирҗанов Ә.* Яшьлеген сагынучы әдип // Мәгариф. 2000. № 2. Б. 34.

67. *Шамсутова А.* Язучы Мөхәммәд Мәһдиев иҗатына бер караш // Казан утлары. 2003. № 12. Б. 107–115.

68. *ШамсутоваА.* Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 205 б.

69. *Шамсутова А.* Фәүзия Бәйрәмова прозасы. Монография. Казан: «Хәтер» нәшрияты. 2005. 120 б.

# ТАТАРСКАЯ И ТУРЕЦКАЯ ЛИТЕРАТУРА В КОНТЕКСТЕ ПОСМОДЕРНИЗМА КОНЦА XX – НАЧАЛА XXI ВЕКА

**Алсу Атласовна Шамсутова**,
Институт языка, литературы и искусства АН РТ,
Россия, 420008, Казань, ул. К. Маркса, д. 12,
aatlas1@mail.ru.

**Мурат Урфет улы Узун**,
Центр Знаний и искусства Измита,
Турция, 41100, г. Измит-Коджаэли, Cem Aydın İlkin Sokak No:3 İzmit - Kocaeli,
tfimuratuzun@gmail.com.

В статье рассматривается творчество современных татарских и турецких писателей рубежа XX–XXI веков в свете постмодернистской концепции. В фокусе внимания автора статьи оказались идейно-эстетическое своебразие их произведений: философские идеи, которые нашли отражение в их творениях, художественные приемы, используемые авторами. Объектом изучения послужила проза татарских писателей Ф. Байрамовой, З. Хакима, Н. Гыйматдиновой, Г. Гильманова, М. Магдиева, Ф. Яхина, турецких писателей И. Анара, О. Памука, А. Шафака, обеспечивающих развитие национальной культуры. Философские взгляды М. Магдиева, Н. Гиматдиновой, Г. Гильманова, З. Хакима, их художественные приемы и эстетические ориентиры рассматриваются в свете культурного и литературного контекста конца XX – начала XXI века, а произведения Ф. Байрамовой и Ф. Яхина интерпретируются в мифологической и метафизической плоскостях, романы турецких писателей – в контексте их связей с арабской и восточными литературами, в рамках канонов постмодернистской поэтики.

В статье систематизированы информация и факты из различных источников, имеющих отношение к постмодернистской парадигме в турецкой литературе; авторы попытались дать обзор современной турецкой литературы. Впервые в научный оборот вводятся произведения современного турецкого писателя Алифа Шафака. Методологической основой исследования послужили сравнительно-исторический, типологический и герменевтический методы. Исследование велось с опорой на лучшие традиции культурно-исторической школы.

**Ключевые слова**: татарская литература, турецкая литература, постмодернизм, мифотворчество, метафизический реализм, нарратив, интертекстуальность, архетипы